Кыю кызлар

Армиядә хезмәт итү хатын-кыз эше түгел дип кем әйтә? Узган елны гына да Татарстаннан контракт буенча 11 хатын-кыз армиягә киткән. Минзәлә районыннан Анастасия Асанованың Көньяк Осетиядә хезмәт итүенә тиздән өч ел тула.

11 БИТ

Гомер буйлап барам...

Айдар Галимов гаилә, иҗат һәм мәхәббәт турында

12 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 22.02.2017 | № 19 (5781)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ТАНКИСТ

Казан танк училищесы мәйданына җиңел генә эләгеп булмый. Ул дәүләт эчендәге дәүләт кебек үз кануннарына буйсынып, үз таләпләре белән яши. Шулай да Ватанны саклаучылар көне алдыннан танк гаскәрләре өчен офицерлар тәрбияләүче Россиядәге бердәнбер уку йорты белән танышу җае чыкты.

10 БИТ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга 66 сум 99 тиен

3 айга 200 сум 97 тиен

6 айга 401 сум 94 тиен

Ташламалы бәядән язылып кал!

һәр айның 15 числосына кадәр язылсагыз, газета киләсе ай башыннан киләчәк.

Синең өчен, синең турында!

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

136 сум 15 тиен 1 айга

408 сум 45 тиен 3 айга

816 сум 90 тиен 6 айга

Реклама

РЕСПУБЛИКАДА

АРЧА

24 февральдә Арчада «Заман» ширкәте территориясендә «Запорожец» автомобильләрендә ярышачаклар. Әлеге бәйге, традиция буенча, Ватанны саклаучылар көне уңаеннан оештырыла.

АЗНАКАЙ

Районда эшләп килүче «Пар канатлар» клубында, ялгызларны кавыштыру максатында, чираттагы чара узган. Бәйрәм барышында бәйгеләрдә сынатмаган катнашучылар: Фәйрүзә белән Рәискә иң зур бүләк – Азнакайның бер кафесында романтик рухтагы кичке ашка чакыру тапшырылган. Ә инде тамашачылар бер-берсенә лаеклы дип тапкан тагын бер парга чаңгы базасыннан махсус бүләк бирелгән.

МЕНДЕЛЕЕВСК

Менделеевск халкы алты еллап көткән автовокзал, ниһаять, ишекләрен ачкан. Транспортны көтеп торучылар өчен барлык шартлар да тудырылган, заманча җиһазландырылган бина 300дән артык кешене сыйдыра. Көн саен автовокзалдан төрле юнәлешләрдә 30лап рейс башкарылыр дип көтелә.

Автовокзал ачылу хөрмәтенә «Менделеевск – Казан» маршруты буенча китүче беренче пассажирларга юл билетларына 50 процент ташлама да ясаганнар.

ТӘТЕШ

Тәтештән Илмира белән Илдар Гайфуллиннар гаиләсендә игезәк балалар туган. Тәтеш районы хакимияте исә яшьләргә бәби чәенә үзенчәлекле бүләк тә ясаган – ике урынлы бала арбасы бүләк иткән.

ЯШЕЛ ҮЗӘН

Мамадыш-Әкил авылында мөгезле эре терлек, башлыча сыер асраучылар саны 200гә кадәр арткан. Халык әйтүенчә, бу – сөт җыю бәясенең литры 20 сумга күтәрелүгә дә бәйле.

ЧАЛЛЫ

Чаллыда 21 көн дәвамында «Әтиләр квесты» уза. Өч көн саен ярышларда катнашучы гаиләләргә төрле биремнәр бирелә: тизлеккә чаңгыда шуу, туктап мишеньгә ату, тюбингта шуу, кул пычкысы белән агач кисү, скакалкада сикерү... Ярыш-уенның максаты – гаиләдә мөнәсәбәтләрне яхшырту, ата белән бала арасын ныгыту.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

Чиплаштыру

Дәүләт ветеринария берләшмәсе узган ел Казанда барлыгы 470ләп йорт хайванын чиплаштырган. Микрочип инъекция ярдәмендә тире астына кертелә. Шул рәвешле һәр хайванга номер тагыла, һәрберсенең «электрон паспорты» барлыкка килә.

Бу хезмәт түләүле. Ветеринария берләшмәсендә 600 сумга чиплаштыралар. Шәхси клиникаларда 100 сумга кадәр җитә икән. 2018 елда Россиядә һәр йорт хайванын бердәй мәгълүматлар базасына кертү күздә тотыла. Чиплаштырылган хайван югалса да, аны илнең теләсә кайсы почмагыннан табарга була, ди. Кайбер ил чиген узганда, үзең белән йорт хайванын алырга уйласаң, аның чиплаштырылган булуын таләп итәләр икән. Ветеринария клиникаларында хайван турындагы барлык авырулары, прививкалар турындагы мәгълүматны да шул чиплар ярдәмендә генә укырга җыеналар.

СЕЗ ҮЗЕГЕЗНЕҢ ЙОРТ ХАЙВАНЫГЫЗНЫ ЧИПЛАШТЫРЫР ИДЕГЕЗМЕ?

Флюра НИЗАМОВА, журналист:

– Шәһәрдә яшәсәм, чиплаштырыр идем. Аның зыяны юк бит. Бу йорт хайваннарын исәпкә алу, табигатьне экологик яктан чисталыкта тоту, хайваннар арасында очрый торган чирләр таралмасын өчен дә мөһим. Беренче чиратта, әлбәттә, йорт хайваннары санын чикләр өчен, этләр, мәчеләр тиешлесеннән артып китсә, хуҗасына салым салыр өчен дә кирәк. Хайваннарны кызганып, 20шәр мәче асрап, күршеләрен интектерүчеләр дә очрый бит. Ә авылда табигый шартларда яшәгән этләр, мәчеләрне чиплаштыру бәлки кирәк тә түгелдер. Авылда болай да, шәһәр белән чагыштырганда, сирәгрәк очрый алар. Минем, мәсәлән, ике мәчем иске йортта яши. Өченчесе – бәләкәе, үзебез белән. Кызганыч, гадәттә, идеяләр яхшы ният белән башлана да, нәтиҗәсе булмый кала.

Айсылу ГАБДИНОВА, җырчы:

– Әгәр зыяны булмаса, бу процедураны авыртырмый гына ясасалар, мин каршы түгел. Беренче чиратта, югалган хайваннарны табарга ярдәм итәр иде ул чиплар. Берсендә мәчемне югалттым. Таба алмадым. Бик озак кәефсезләнеп йөрдем. Урамда югалган йорт хайваннарын еш очратырга туры килә. Хуҗасыз этләрне, мәчеләрне күрү бик кызганыч. Чиплаштыру бу мәсьәләдә ярдәм итәр иде.

Айрат КАМАЛОВ, пенсионер:

– Шәһәрләр чиплаштырсыннар. Ә авыл җирендәге хайваннарга кирәкле нәрсә дип уйламыйм. Ул хезмәт өчен артык 600 сум акчабыз да юк. Болай да эт көне буе бәйдә тора. Мәчене куып чыгарсаң да кире кайта. Ә менә шәһәрдә фәлән меңгә сатып алынган мәчеләре югалса, чынлап та бәла.

Виталий Чуркин вафат

Дүшәмбе көнне Нью-Йоркта, 65 яше тулырга бер көн кала, Россиянең Берләшкән милләтләр оешмасы каршындагы даими вәкиле Виталий Чуркин вафат булды. Ул йөрәк өянәгеннән үлгән дип фаразлыйлар. Аның хәле эш вакытында начарланган, клиникада җан биргән.

Виталий Чуркин вафатыннан соң, Мәскәүдә аңа һәйкәл куярга кирәк, дигән идея дә яңгырады. Әлеге тәкъдим белән җәмәгать оешмалары чыккан. Дипломат истәлеген мәңгеләштерү уңаеннан мемориаль такта кую фикере дә бар.

Россия Президенты Владимир Путин Виталий Чуркинны үлеменнән соң «Батырлык ордены» белән бүләкләү турында карарга кул куйган, дип яза ТАСС. Кремль матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, бүләк «АКШ, Нью-Йоркта Россия Федерациясенең Берләшкән милләтләр оешмасы каршындагы даими вәкиле постында күрсәткән фидакарьлеге, ныклыгы һәм югары һөнәри осталыгы өчен» бирелә.

Шәһәр кәефе

РАФАИЛ СӘГЕТДИНОВ, отставкадагы подполковник:

– Ир-егетләр хәрби хезмәттән куркырга тиеш түгел. Армиядән дөнья күреп, чыныгып кайтасың. Якташларыбыз исән-имин хезмәт итсеннәр, дип телим. Россия кораллы көчләренең куәте, дәрәҗәсе арта баруына сөенәм. Элеккеге хезмәттәшләремне, булачак солдатларны Ватанны саклаучылар көне белән котлыйм! Илдә тынычлык булсын! Тыныч үсештә Казан Олимпия уеннарын да үзендә кабул итәр әле.

ЛИНА ЗИННӘТУЛЛИНА, тележурналист:

– Әстерханда туганмын, ләкин миңа ике яшь чагында гаиләбез Татарстанга күченеп кайткан. Казанда үстем, үземне Казан кызы дип саныйм. Күңелемдә Әстерханга да җылы хисләр саклана. Музыка тыңларга яратам, гитарада уйныйм. Кышын да, җәен дә ял көннәрендә паркта бернечә чакрымга йөгерәм. Йөгерергә исәпләсәгез, онытмагыз, беренче тотынганда ерак арага йөгермәгез. Чакрымнарны аз-азлап яулагыз.

ФИРДӘҮС ШАКИРҖАНОВА, пенсионер:

– Армиягә, хәрбиләргә хөрмәтем зур. Ирем Мәүхәт Бөек Ватан сугышында катнашты. Аның белән сөеп-сөенешеп яшәп, балалар үстердек. Әле онысым яңарак кына хәрби хезмәттән кайтты. Гаиләбездә шатлык. Мәүхәт кенә арабызда юк, гаҗәеп тәртипле, кин холыклы җан иде. Мәүхәтемне бик сагынам, юксынам. Ир белән хатын бер-берсенә нык иярләшә бит ул. Яшьләргә бездән фатиха, сугышлар чыга күрмәсен.

АЙНАЗ СӨБХӘНГУЛОВА, аспирант:

– Һөнәрем компьютер программалары белән бәйле. Өлкәннәр «булмый» дип шикләнмәсеннәр, компьютерда эшләргә өйрәнсеннәр. Коммуналь түләүләр башкарырга, табибка язылырга өйрәнсеннәр. Азапланып барып йөргәнче, шул эшне өйдә дә башкарып була лабаса. Тик кечкенә балалар телевизор, компьютер алдында көненә ике сәгатьтән дә артык утырмасыннар. Колакчын белән көне буе музыка тыңлау да сәламәтлеккә зарарлы.

АЛЕКСАНДР КОМКОВ, пенсионер:

– Казанда туып-үстем. Югары белем алганнан соң, Сахалинда хәрби хезмәттә булдым. Текә кыядан диңгезгә вак таш ыргытаыргыта Казанны сагынуым бүгенгедәй истә. Сахалинны, хезмәт иткән урыннарны тагын бер күреп кайтсаң ярар иде дә, билет чамадан тыш кыйммәт шул. Гомер сизелми дә узып китә. Казанда милләтләр һәм диннәр дуслыгына күз тимәсен. Илләр-халыклар сугышып түгел, туганлашып яшәсен иде.

Ир балалар өчен пансионат

Яңа уку елына Балтач районының Борбаш авылында ишле һәм аз керемле гаиләләрдә тәрбияләнүче малайлар өчен пансионат ачылачак. Анда республиканың барлык районнарыннан җыелган 40 бала тәрбияләнәчәк. «Ярдәм» милли ислам хәйрия фондының идарә рәисе Илһам Исмәгыйлев «ШК»га сөйләгәнчә, пансионатның төп максаты – ишле, аз keремле гаиләләрдә тәрбияләнүче сәләтле балаларны җыеп укыту, аларга дини тәрбия бирү.

Фото бизәү өчен бирелде

– Баланың сәләте булырга, әмма аны үстерергә гаиләнең мөмкинлеге булмаска мөмкин. Без менә шундый гаиләләргә булышырга телибез. Пансионат өчен Борбаш авылының иске мәктәп бинасын алдык, ул 714 квадрат метр мәйданны алып тора. Интернат формасында эшләячәк. Хәзерге вакытта анда төзекләндерү эшләре бара. Акча ягыннан кыенлыклар килеп чыкмаса, яңа уку елына өлгерербез дип торабыз. Безнең исәпләүләр буенча, әлеге проектны гамәлгә ашыру өчен 15 миллион сум акча кирәк. Ярдәм итәргә теләүчеләр булса, безгә мөрәҗәгать итсеннәр, хезмәттәшлек итәргә әзербез, – диде ул.

Пансионатка V-VI сыйныфтан кабул итәргә ниятләп торалар. Янәшәдә генә яңа гына төзелгән заманча мәктәп бар. Алар шунда белем алачак.

– Пансионатның татар авылында урнашуының үзенә бер хикмәте бар. Монда балалар татарча тәрбияләнәчәк. Уку йорты дини юнәлештә эшләр дип торабыз. Анда тәрбияләнүчеләрне киләчәктә мәдрәсәләрдә укучылар итеп күрәсе килә. Мәдрәсәләргә күп балалар әзерлексез килә. Ә боларның башлангыч белеме булачак. Болгар ислам академиясенә дә бит сәләтле, укымышлы егетләр кирәк була, – ди шушы авылның имамы, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев.

Проект үзенең нәтиҗәлелеген күрсәтсә, алга таба Татарстанның башка районнарында һәм кызлар өчен дә пансионатлар ачылу күздә тотыла.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Кабат «Үзгәреш җиле»

Казан дәүләт мәдәният университетында икенче тапкыр үтәчәк «Үзгәреш җиле» масштаблы татар җыры фестивален сәхнәгә әзерләнәләр. Искәртик, «Үзгәреш җиле»нең беренчесе Казанда һәм Мәскәүдә 2016 ел ахырында үтте.

Фестивальнең баш сайлап алучысы – танылган җырчы һәм педагог Венера Ганиева репетицияләрнең беренче фестивальдәге башкаручыларның яртысы белән үтүе хакында сөйләде.

– Болар – беренче фестивальдә катнашкан 14 кеше. Без яңа репертуар сайладык һәм концертмейстерлар белән эшли башладык, – дип аңлаткан Венера Ганиева «Татар-информ» хәбәрчесенә.

РСФСРның һәм Татарстанның халык артисты 1 марттан яңа башкаручыларны тыңлый башлаячаклары турында әйткән. «Яңа башкаручыларны җыячакбыз, аранжировкалар ясаячакбыз һәм яздырачакбыз», – ди ул. Репетицияләр исә университетта, шулай ук Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында барачак.

Грипп чигенә

Соңгы бер атна эчендә Татарстанда 25 меңгә якын кешедә кискен тын юллары вирусы һәм грипп ачыкланган.

oren.ru

Роспотребнадзорның Татарстан идарәсе матбугат үзәге хәбәр итүенчә, ел башыннан бирле беренче тапкыр авыру эпидемия чигеннән түбәнрәк төшкән. Узган атна белән чагыштырганда, кискен тын юллары вируслы инфекциясе һәм грипп белән авыручылар саны 6,2 процентка кимегән.

Грипп чигенә башласа да, уяулыкны югалтмаска киңәш итә белгечләр. Авыруны йоктырмас өчен, бүлмәләрне ешрак җилләтергә, кулларны юып йөрергә, кеше күп булган урыннарда махсус битлек кияргә, барлык саклану чараларын да файдаланырга кирәк.

КҮРШЕЛӘРДӘ

Уфада тәмәке тартучыларга каршы үзенчәлекле «көрәш» башлаганнар. Бер хәйрия фонды тартучыларга тәмәкеләрен сөткә, йә сокка алыштырырга тәкъдим итә. Ә үзләрендә тәмәке тартуны ташларга көч тапканнарга Уфа тренажер залларының берсенә бушлай абонементлар биреләчәк.

Чабаксар шәһәренең үзәгендә дистәләрчә еллар буе торган металл гаражлардан арына башлаганнар. Законсыз салынган гаражларны сүтүдә авырлыклар да бар икән, еш кына аларның хуҗасын табу кыенлыклар тудыра. Хуҗасыз металл корылмалар язмышы суд аша хәл ителсә, сүтелгән гараж хуҗаларына башка урыннан җир кишәрлекләре тәкъдим итәләр.

Мари Элда троллейбуслар йөрүдән туктарга мөмкин. «Троллейбус транспорты» предприятиесе җитәкчелегенең энергиягә түләү буенча 80 миллионнан артык бурычы җыелган. Шуңа да электр белән тәэмин итүдә чикләүләр кертергә җыеналар. Әлегә троллейбуслар билгеле бер сәгатьләрдә генә маршрут буенча юлга чыгачак, дип хәбәр итә «Комсомольская правда».

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

ТОП – 3

ҮЗӘК Банк совет мультипликациясенә багышлап берничә коллекцион монета чыгарырга уйлый. Алар барлыгы 300 мең данәдә басылыр дип көтелә, дип хәбәр итә «Вести» сайты. 3 һәм 25 сумлык тимер акчаларда «Ну, погоди!» мультфильмыннан куян белән бүрене, Винни Пух, Пятачок, Простоквашино мультфильмыннан Дядя Федор, шулай ук Чебурашка, Гена исемле Крокодилны, Леопольд мәчесен һәм башкаларны күреп булачак, ди. Бу акчалар 2017 елның азагына кадәр дөнья күрер, дип ниятләнелә.

ТАТАРСТАН Президенты Рөстәм Миңнеханов указы нигезендә, җырчы МакSимга «Музыка сәнгатенә керткән өлеше һәм нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен» «Татарстан Республикасының атказанган артисты» исеме бирелгән, дип хәбәр итә Татарстанның Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге матбугат хезмәте. Җырчы мәртәбәле исем өчен рәхмәтен җиткереп, иҗат кешесе өчен югары дәрәҗәдә танылу мөһим дип белдергән.

КАЗАН прокуратурасы наркологта исәптә торган, җитди авыруы булган автомобиль йөртүчеләрне машина йөртү таныклыгыннан мәхрүм итәргә кирәк дип саный. Закон нигезендә кешенең наркоман, токсикоман булуы, алкоголь эчемлекләр куллануы, медицина күзлегеннән караганда, машина йөртүне тыя торган күрсәткечләр.

АКТУАЛЬ ТЕМА

Балам, тәмлеме боткаң?

vk.com

21 февральдә Казанның 405нче балалар бакчасындагы меню

Күләме	Ризык атамасы	Күләме
(1-3 яшь)	**Иртәнге аш**	**(3-7 яшь)**
150/4	Сөттә пешерелгән арпа боткасы	200/5
160	Сөтле какао	180
25/5/5	Сыр, май белән бутерброд	30/7/5
	Икенче иртәнге аш	
95	Сок	95
	Әбәт	
150/5	Итле шулпада пешкән борщ	200/7
150	Пешкән иттән пылау	200
130	Кесәл	150
30	Авыл ипие	37,5
–	Бодай икмәге	30
	Кичке әбәт	
17,5	Кондитер әйберләре	40
110	Ряженка	130/2
20	Кишер һәм кургәгдән салат	30
70	Банан	70
70/10	Куертылган сөт һәм эремчектән суфле	80/15
100/4/2,5	Шикәрле, лимонлы чәй	120/5/3
10	Бодай икмәге	10

Соңгы атналарда гомумбелем бирү учреждениеләрендә балаларның һәм укучыларның туклануына бәйле темалар көнүзәк мәсьәләгә әйләнде. Моның берничә сәбәбе бар. Беренчедән, соңгы бер-ике елда бу тармакта шактый гына үзгәрешләр булды. Ә яңалык, үзегез беләсез, тиз һәм шома гына кабул ителми. Сентябрьдән Казанның Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты менюларына шактый үзгәрешләр кертелү сәбәпле, әти-әниләрнең сораулары да артты. Берничә көн элек балаларның туклануы мәсьәләсе Татарстан Дәүләт Советының социаль сәясәт буенча комитеты утырышында да каралды.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Балалар бакчаларында ит, балык киметелде, ә кәбестә, кишернең күләме, киресенчә, артты, балалар бакчадан ач кайта, кебек шикаятьләрне үземә дә берничә тапкыр ишетергә туры килде. Алар нигезлеме соң, гомумән, балалар бакчаларында туклану мәсьәләсе ничек оештырылган? Шул хакта тулырак мәгълүмат туплар һәм барысын да үз күзләрем белән күрер өчен, Казанның катнаш төрдәге 405нче балалар бакчасына юл алдым.

«БАЛАЛАР ЯШЕЛЧӘ АШАРГА ӨЙРӘНМӘГӘН»

Мөдир Дания Гаязова аңлатуынча, департамент балалар бакчаларына ун көнлек меню тәкъдим итә. Әмма бу да әле төп-төгәл эшләнеп беткән ахыргы вариант түгел, алар һаман үзгәртелеп тора. Мәсәлән, уку елы башында балаларның менюларында, чыннан да, ит, балык кимегелгән, кәбестә, кишер кебек яшелчәләрнең күләме арттырылган иде. Соңыннан, әти-әниләрдән килгән күп шикаятьләр искә алынып, яшелчәләр киметелгән.

– Балалар яшелчә ашарга өйрәнмәгән, чөнки өйдә алар аны аз куллана. Әмма яшь организмга ул бик кирәк. Кечкенәләр пешкән кәбестә, кишер ашарга яратмасалар да, чи яшелчәләрдән ясалган салат тәлинкәләрен «ялт» иттерәләр.

– Ит күләме кимеде, дигән сүзләр дөреслеккә туры киләме соң? Соңгы айларда менюга нинди үзгәрешләр кертелде?

– Әйе, ул бераз кимеде. Хәзер шулпада пешкән итне икенче аш ризыгына файдаланабыз. Моннан кала, гыйнварда үзгәртелгән менюда ризыкларның урыны алыштырылды. Моңа кадәр кич ашый торган ризык хәзер төшке аш вакытында бирелә. Әмма соклар, җиләк-җимешнең (алма, әфлисун, банан) күләме артты. Элек сок яки җиләк-җимеш кенә бирәләр иде, хәзер менюда көн саен икесе дә бар. Февральдә 12,5 сәгатьлек төркемнәр бетерелеп, 10,5 сәгатьлеккә калдырылгач, менюга да үзгәрешләр кертелде. Нәтиҗәдә кичке аш бетерелде, ә кичке әбәт туклыклырак итеп бирелә башлады. Моннан кала, бу айдан башлап, безнең бакча хәләл менюга күчте, – дип аңлатты ул.

Пешерүчеләр Зимфира Мөхәммәтҗанова белән Эльмира Фазылҗанова әйтүенчә, департамент тарафыннан барысы да үз вакытында эшләнелә. Сөт ризыкларын кич китерсәләр, ипине иртән алып киләләр.

– Кул токмачы салып пешерелгән ашны балалар аеруча яратып ашый, ләкин ул, беренчедән, мәшәкатьлерәк булса, икенчедән, бездә аны киптерер өчен шартлар юк. Шуңа күрә әзер кибет токмачына алыштырып булмасмы икән, дигән мәсьәләне күтәреп чыккан идек. Әлегә моның буенча ахыргы сүз әйтелмәде, – ди алар.

Башка ата-аналардан бакчада яки мәктәптә пешерелә торган ризыкның тәмсез булуы турында да ишеткән бар иде. Шуңа күрә монда баргач, ике бала әнисе буларак, пешергән ризыкларыннан үзем дә авыз иттем. Телеңне йотарлык ризыкка бер генә дә тел-теш тидерерлек түгел! Монда, әлбәттә, пешерүчедән күп нәрсә тора. Кызлар, афәрин! Әмма шулай да пешерүчеләр сүзләренә караганда, билгеле бер ризыкны, ничек кенә тәмле итеп пешерсәң дә, балаларның күпчелеге аны яратмый, ди. Мәсәлән, минтай кәтлитен ашамыйлар икән, тик департамент күбесенчә нәкъ менә шул балыкка заказ бирә. Ә менә кызыл балыктан әзерләнгән суфлены барысы да диярлек бик яратып ашый.

> Татарстанның премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры **Энгель ФӘТТАХОВ:**
>
>
>
> – Без – үсеш алган аграр республика. Шулай була торып, әлегә кадәр кайбер муниципаль берәмлекләрдә балаларның туклану процессын оештыра алмавыбыз гаҗәп. Сезнең өчен (муниципаль мәгариф идарәсе җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп. – **Ред.**) бу намус эше булырга тиеш, ә без әле хәзер дә ата-аналардан туклану продуктлары сыйфатына бәйле шикаятьләр алабыз. Мин кыска вакыт эчендә әлеге өлкәдә тәртип урнаштыруны таләп итәм.

СЕЗОННЫ ТУКЛАНУ

Казанның балалар бакчаларындагы меню, сезонга бәйле рәвештә, елга дүрт-биш тапкыр үзгәртелә. Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты директоры Гүзәл Ананьева әйтүенчә, гыйнвардан кабак, ташкабак, помидор-кыярны кәбестә, кишер һәм чөгендер алыштырган. Моннан тыш, ризыкларга яшел тәмләткечләр дә кушыла. Әлеге үзгәрешләр Казанның 465 учреждениесенә һәм республиканың тугыз районына кагыла. Балалар бакчаларына тиләү арту тәүлегенә кабул ителә торган җиләк-җимеш, кипкән җиләк-җимеш, сок, ит, сөт ризыклары һәм сырларның күләмен арттырырга мөмкинлек биргән.

– Гыйнвардан ризыкларның бер тәүлеккә исәпләнгән күләме 97 граммга артып, 1782 граммны тәшкил итте. Кайбер әти-әниләр, менюдагы үзгәрешләр нәтиҗәсендә, ит кимеде, ә яшелчәләр артты, дип саный. Бу дөреслеккә туры килми, – ди ул.

«ШИКАЯТЬЛӘРНЕҢ КҮБЕСЕ НИГЕЗЛЕ»

Татарстанда 1,4 меңгә якын гомумбелем бирү оешмасы исәпләнелә, аларда 385 меңнән артык бала һәм яшүсмер белем ала. Былтыргы уку елында укучыларның 95,9 проценты кайнар ризык белән тәэмин ителгән. Бәяләренә килгәндә, алар һәр районда төрлечә билгеләнелә, әмма уртача алганда ул 27,6 сумны тәшкил итә. Казанда, мәсәлән, Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты аша җайга салынган үзәкләштерелгән туклану системасы оештырылган 92 мәктәптә иртәнге аш – 22 сум, төшке аш – 58 сум. Әмма бала саен һәркөн бюджеттан өстәлә торган бәя бөтен җирдә дә бертөрле. Быелның 1 гыйнварыннан ул – 6 сум 80 тиен.

Дөрес, күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче укучыларга бушлай туклану мөмкинлеге бирелә. Әмма күп балалылык республиканың төрле районында төрлечә билгеләнелә. Мәсәлән, 16 районда мондый бәхет дүрт һәм аннан күбрәк балалары булганнарга гына тәтесә, Чаллыда исә, бушлай туклану хокукына ия булыр өчен, гаиләдә биш һәм аннан да күбрәк бала булу шарт. Ә калган шәһәр һәм районнарда гаиләдә өч баладан күбрәк булганнар бушлай ашый ала.

– Без, ишле гаилә буларак, мәктәптә бушлай ашыйбыз. Тик моңа ирешер өчен нинди юллар узганымны үзем генә беләм. Хокукларымны дәгъвалап, Мәгариф һәм фән министрлыгына кадәр шалтыратырга туры килде хәтта. Сентябрьдә гариза язып тапшырсак та, бушлай ашау бәхетенә ноябрьдә генә ирештек. Балалар Киров районының 137нче мәктәбендә укый. Ризыкларның сыйфатына телтеш тидерерлек түгел анысы. Балалар яратып ашый. Өйдә кәбестә, чөгендер салатлары ашамасалар да, мәктәптә сыпыртып куялар. Еш кына соклар, җиләк-җимеш, баллы ризыклар бирәләр. Әмма дәресләр күп, мәктәптә бер тапкыр гына ашау җитми, шунлыктан үзләре белән өйдән дә алып китәләр, – ди өч бала әнисе Диләрә Низамова.

Татарстан Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты депутатлары, Роспотребнадзор белән берлектә, мәктәп ашханәләренә ел дәвамында тикшерүләр белән барган. Шушы көннәрдә аның нәтиҗәләре дә игълан ителде. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Марина Патяшина сүзләренә караганда, соңгы ике елда әти-әниләрдән 25 мөрәҗәгать кабул ителгән һәм шуларның 20се исбатланган. Беренче проблема – туклану сыйфаты булса, икенчесе – ризыкларның, аеруча ит ризыкларының күләмнәре күрсәтелгәннән азрак булуы ачыкланган.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

«Без аны җибәрмибез»



Беркөнне редакциягә Константиновка бистәсеннән мөрәҗәгать иттеләр. «Безнең Әлмирага ярдәм итә алмассызмы? Бик начар шартларда яши. Ә иң авыры – аяклары сызлый. Аңа медицина ярдәме кирәк, тик хастаханәләрдә кабул итмиләр, чөнки документлары юк», – диде күршеләре. Хат эзеннән бистәнең Озерная урамына кузгалдык.

Язмабыз герое безне урамда ук каршы алды. Табуреткасына таянган, бер кулында себерке. Һәр җомгада шулай подъездларны, ишегалларын тәртипкә сала икән. Җомганы изге көн дип кабул итүе Үзбәкстанда яшәгән чагыннан ук килә. Татарстанга күченгәненә дә 18 еллап икән инде.

«Әти-әнием тумышы белән Яшел Үзәннән», – дип сөйли башлады Әлмира Гобәйдуллина үзе турында. Подъезд төбендә урындыгын күршесе биреп торган инвалидлар өчен махсус җайланма – ходункига алыштырды, баскычларга җиткәч, таякка үрелде. Гаҗәпләнгәнебезне күреп: «Шулай җайлашасың инде, ничек булса да хәрәкәтләнергә кирәк бит», – дип, авырлык белән икенче катка атлады. Аңа әле 49 гына яшь. Үзбәкстанда чакта әти-әнисе белән төзелештә йөргән, бәйләү, тегү фабрикасында эшләгән. Бәхет эзләп, Татарстанга кайткан. 2000 елларда, Константиновка бистәсендә яшәгәндә, янгын чыгып, барлык документлары көлгә әйләнгән. Бөтен күңелсезлекләре шуннан башланган да бугай. Аннан соң базарда сату иткәндә, башына караклар суккан. Катлаулы җәрәхәт эзсез узмаган – баштагы авырту тора-бара аякларына төшкән. Хәзер менә тураеп баса да алмый, урындык, таяк ярдәмендә генә хәрәкәтләнә. Бер ир-атка йортка кергән булган, тик аның белән дә озак яши алмаган. Ире күптән гүр иясе. Иренең беренче хатыныннан туган улы, кызганып, әтисе фатирының бер бүлмәсенә урнаштырган.

– Әле ярый ул ярдәм итте. Күрше бүлмәдә гаиләсе белән алар яши. Бик салкыннарда үзләрендә кундыралар, – дип сөйли Әлмира апа.

Әңгәмәдәшем яшәгән торакка узабыз. Кечкенә генә бүлмәдә бер өстәл, суыткыч, карават, шкаф, электр плитәсе. Бәдрәф, юыну урыны юк. Бүлмәгә җылылык, су кертелмәгән. Без сөйләшкән арада, йортның идарәчесе Рәйсә апа да кереп җит те.

– Мин биредә әле берничә генә ел яшим. Йортка инде 60 ел тирәсе. Монда элек мич ягып гомер иткәннәр. Тузган торак дип сүтәргә дә уйлаган булганнар, тик яшәүчеләр күченәселәре килмичә каршы торганнар. Нәтиҗәдә әле бер ел элек кенә йортка капиталь ремонт ясый башладылар. Җылылыкны һәркем фатирына үзе сузган, суны да үзе керткән. Мөмкинлеге булмагач, Әлмира сусыз да, җылылыксыз да калган. Шулай да ул кулыннан килгән кадәр тырыша, бүлмәсен үзенчә җыештыра. Суыткычы тулы ризык. Күршеләре бик булыша, – ди Рәйсә ханым.

Ул да түгел, бүлмәгә шул йортта яшәүче бер әби килеп керде. Күршеләрен без алып китәргә килгән дип уйлап:

– Беркая да бармый Әлмира. Без аны җибәрмибез. Ул бик әйбәт кеше. Менә ике метрлы әзмәвердәй күршеләребез подъезд идәнен дә себергәннәре юк, ә ул, аяклары авыртса да, юып ук чыгара. Тәртип бозмый, янына бер ир-атның да килгәне юк. Җылытабыз да без аны, ашатабыз да, суын да бирәбез. Алып кына китмәгез, – дип өзгәләнергә тотынды ак шәлле әби.

Халидә әби астагы катта яши икән, 70 яшь үзенә. Аның җылы сүзләреннән Әлмира апаның да күзләре яшьләнде. Үзе турында күптән мондый ягымлы сүзләр ишетмәгән хатын, елый-елый, күршеләренә рәхмәт укыды. Алып китәр өчен түгел, ярдәм итәргә килгәнлекне аңлатканнан соң, Халидә әби җомгага дип пешергән коймаклары белән дә сыйлады әле үзебезне.

Ярдәмгә килгәндә, паспорт алу мәсьәләсе без уйлаганнан катлаулырак булып чыкты. Беренчедән, Әлмира Гобәйдуллинаның паспортсыз яши башлавына 15 еллап вакыт узган, җитмәсә бер туганы да, әти-әнисе дә исән түгел. Икенчедән, Үзбәкстаннан күченеп кайткан кеше турында сүз бара. Шуңа да без Татарстанның Халыклар дуслыгы йортына мөрәҗәгать иттек. Медицина ярдәмен күрсәтүне оештыруны сорап, Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгына мөрәҗәгать юлладык. Сезне дә әлеге вакыйгага кагылышлы хәбәрләр белән таныштырып барырбыз.

Татарстан Халыклар дуслыгы йорты директоры, Дәүләт Советы депутаты **Ирек ШӘРИПОВ:**

– Халыклар дуслыгы йортында Үзбәкләрнең милли-мәдәни автономиясе юридик һәм консуллык ярдәме күрсәтә. «Шәһри Казан» газетасы мөрәҗәгате белән, без аларга авыр хәлдә калган әлеге ханым турында хәбәр иттек. Безнең үтенеч белән якын көннәрдә юристлар Әлмира Гобәйдуллина янына барып мәсьәләне өйрәнәчәкләр, кирәкле мәгълүмат туплаячаклар. Паспорт мәсьәләсендә белгечләр йә Мәскәүдәге Үзбәк консуллыгы, йә Үзбәкстан хакимияте белән элемтәгә чыгачаклар. Бу эшне контрольдә тотарбыз.

Эльвира МОЗАФФАР.

Кызыксындырган сорауларыгызны редакциягә **(843) 562-50-03, 8(917) 851-69-62** телефоннары аша җиткерә аласыз.

Пенсия өлкәсендәге үзгәрешләргә багышланган язмада (№13, 9 февраль), стажы булмаган кешеләргә дә 7898 сум пенсия биреләчәк, дип язгансыз. Мин 1951 елгы. Гомер буе эшләп тә, 6348 сум гына пенсия алам. Нинди гаделсезлек инде бу? Өстәвенә III группа инвалидлыгым бар. Бер дару 1 мең сумнан артык тора. Ул пенсия акчасына ничек яшәргә? Яшәү минимумыннан да азрак булып чыга бит.

Зөлфия ХӨСНЕТДИНОВА,
Питрәч районы, Шәле авылы.

Кайбер сәбәпләр аркасында, кешенең картлык буенча пенсиягә чыгар өчен стажы, баллы җитеп бетми икән, аңа 7898 сум социаль пенсия билгеләнә. Бу хакта, сез искәрткәнчә, газетабызның узган саннарының берсендә язган идек. Ул акчаларны, картлык буенча пенсия яше җитсә дә, бары биш елдан соң гына алырга була. Ягъни ир-атларга ул – 65, хатын-кызларга бары 60 яшьтән соң гына бирелә. Үзегезне III группа инвалид дип язгансыз, картлык буенча пенсиягә чыккан булып та саналасыз. Закон нигезендә, бу ике пенсиянең берсен генә алырга хокукыгыз бар. Пенсия фондының Питрәч районы идарәсенең җитәкчесе Искәндәр Әхмәтҗанов сезнең очракта картлык буенча пенсия алу отышлырак дип саный. «Зөлфия Хөснетдиновaның картлык буенча пенсиясе – 6691 сум, моңа өстәп, федераль ташламага ия гражданнарга тиешле айлык түләүләр (ЕДВ) 2022 сумны тәшкил итә. Айлык акча 8714 сум килеп чыга», – дип аңлатты ул «ШК»га. Вахитов районы пенсия бүлекчәсеннән алынган мәгълүматлар буенча, Татарстан Республикасының 68нче кануны буенча (2016 елның 29 сентябреннән) пенсиягә кушып бирелә торган федераль социаль өстәмә түләүләрнең күләмен исәпләгәндә, пенсионерлар өчен яшәү минимумы билгеләнә. 2017 елга республикада ул 8232 сумны тәшкил итә.

2нче Азино микрорайонында яңа мәктәп төзелеп килә. Бу мәктәпкә эләгү өчен, документларны кая тапшырырга була? Аны кайчан ачарга ниятлиләр?

Гөлнур ГЫЙНИЯТУЛЛИНА,
Казан.

– Совет районы мәгариф бүлегеннән алынган мәгълүматлар буенча, мәктәпне 2017 елның 1 сентябрендә ачарга ниятлиләр. Мәктәп 1224 укучыга исәпләнгән булачак. Әлегә нинди юнәлештә эшләячәге билгеле түгел. Бу ата-аналарның тәкъдимен истә тотып хәл ителәчәк. Мәгариф учреждениесе төзелеп бетеп, юридик яктан теркәлмичә, документлар тапшыру мөмкин түгел. Мәктәп белән бәйле документлар хәл ителгәч, гаризаларны да шул мәктәптә кабул итәчәкләр. Ата-аналар өчен аңлату чарасы уздырылачак.

«Россиядә мәгариф турында»гы 273нче федераль закон нигезендә, баланы мәктәпкә кабул итү кагыйдәләре билгеләнгән. Аның буенча, һәр баланың яшәү территориясенә кергән белем бирү йортында укырга хокукы бар. Билгеле бер мәктәпнең кайсы территориягә кергәнлеге шәһәр мәгариф идарәсе тарафыннан раслана.

Шулай яшәргә кирәк

Бу авыл яныннан дистәләрчә тапкыр узган булсам да, олы юлдан читкәрәк алып кереп чыгарга ничектер җае туры килгәне юк иде. Бу юлы исә махсус бардым. Кукмара районының бер читендә урнашкан Пчеловод исемле керәшен татарлары авылы бу. Искиткеч төзек, матур авыл. Балтач–Шәмәрдән юлыннан барганда уң якта кала торган кечкенә генә сала үзенең яшәеше белән гаҗәпкә калдыра.

АВЫЛ

Илфак ШИҺАПОВ

Заманында ерак түгел урнашкан Көшкәтбаш авылы халкы күчкән монда. Риваятьләргә караганда, утрау кебек урынга башта бер урыс урнашып хутор корган, аннан соң аның янына берничә урыс һәм керәшен татарлары күченгән. Төп авыл булып саналган Көшкәтбашта исә бүген ике генә йорт калган.

Пчеловодта 68 хуҗалыкта 250ләп кеше яши. Мәктәп яшендәге 30лап бала бар. Үзләрендә мәктәп юк, балалар йә Чура авылына, йә янәшәдәге Шәмәрдән бистәсенә йөреп укыйлар. Пчеловод, нигездә, озын гына бер урам инде ул. Ләкин нинди!

Монда җимерек яки иске йорт күрмәссең, барысы да, картлар әйтмешли, гүрничәдәй, хуҗалык саен машина, трактор. Урамнар чиста. Көне буе эзләнеп йөрсәң дә, авылда бер исерек тә очрата алмыйсың, халык эшкә чумган.

Поршур авылыннан килен булып төшкән 25 ел биредә яшәүче Лариса Александровадан авыл, яшәеш турында сорашам.

– Халык тырыш бездә, – диде ул, минем сорауларга аптырабрак. – Бар да эшли. Эчәргә вакытлары юк. Элек совет чорында әз-мәз булгалый иде кебек, хәзер юк. Эчмиләр, эчкән кешегә ихтирам белән дә карамыйлар. Нинди кызыгы бар соң эчүнең? Берсеннән-берсе күреп тырыша безнекеләр. Халык динле. Күпләр Чура чиркәвенә йөри. Анда әле күптән түгел олы коену урыны да ясадылар. Уразаны да тоталар Пчеловодта. Бәйрәмнәрне дә бәйрәм итә беләбез без. Шул ук Пасханы, Питрауны зурлап үткәрәбез... Башка бәйрәмнәр дә бик күңелле уза.

Болай яшәр өчен акча кирәк, акча булсын өчен эш кирәк. Баксаң, Пчеловодта күпләр җирле хуҗалыкта түгел, ә үзләренә эшлиләр икән. Күп халык үз пай җирләрен алып эшкәртә, кем күпләп умарта тота, кем – теплица... Дистәдән артык фермер яки крестьян хуҗалыгы бар. Шактый гына хатын-кыз Казанга хастаханәләргә эшкә йөри. Сәбәбе – бер тәүлек эшләп, өч көн үз эшләреңне эшләргә мөмкинлек булуда. Өч көн өйдә берсе дә тик тормый аларның. Гомумән, пчеловодлылар өчен яшәү мәгънәсе – эштә, дигән фикер калды.

Авыл уртасында матур, йөз урынлы яңа клуб. 2013 елда салынган. Кукмара районы хакимият башлыгы Сергей Дмитриевның шушы авылдан булуы искә төшеп, башка бераз көфер уйлар килде. Әллә башлык үз авылын «тартамы»?

Алай дигәч, Лариса кычкырып көлде генә.

– Сергей Дмитриевич глава булгач, безгә ул сүзне әйткәләделәр инде. Беләсеңме, бу сорауга бездә ничек җавап бирәләр? «Кукмара районында да җитешсезлекләр җитәрлек-тер, ярдәмгә мохтаҗлар да бардыр. Сергей әнә аларга ярдәм итсен, без үзебез дә начар яшәмибез», – диләр.

Глава дигәннән, Сергей Дмитриевның әти-әнисе әле хәзер дә бу авылда яши. Искиткеч тырыш, тәртипле гаилә, дииделәр алар турында. Раиса Григорьевна белән Дмитрий Петрович бүген дә ике сыер, үгезләр, күпләп кош-корт асрап яталар. Исемнәрен болай итеп язуым аларның глава ата-анасы булуыннан түгел, монда бөтен кешегә шулай зурлап дәшәләр. Раиса Григорьевна турында кызык кына итеп: «И-и-и, ул бит йөзләгән чебеш-тавык үстерә дә тирә-күршеләрендә яшәгән карт-корының туган көннәренә дә тавык бүләк итә. Бик кешелекле гаилә», – диделәр.

Эре фермерлар да бар авылда. Мәсәлән, шушы авыл кешесе Роберт Дмитриев. Борис Захаров та җирләр эшкәртә, башка бик күпләр дә. Күптән түгел, әнисе шушы авылдан чыккан бер эшмәкәр сэндвич панельләр, пенопластлар эшли торган завод төзеткән. Анда да эш бар. Авыл клубында җыештыручы булып эшләүче Людмила Захарова белән сөйләшәбез:

– Соң, мин дә тырышам инде. Эшем бар дип кенә булмый бит. Кыштан өйдә, парникта рассада үстерә башлыйм, аны сатам. Мал-туар да асрыйбыз. Яшәргә кирәк, балаларга ярдәм итәргә кирәк. Тормышның башка нинди мәгънәсе бар соң? – диде ул да, шулай ук аптырабрак.

Мал-туар дигәннән, аны асраудан да керемне ала белләр Пчеловодта. Әйтик, Лариса Александрова үзенең җәен-кышын сөт тапшыруын, җәен сөттән генә аена – 10-12, кышын 6-7 мең сум акча алуын әйтте. Ә бит авылда бер генә түгел, өч-дүрт сыер, сигез-тугыз үгез асраучылар да бар. Нишләп матур яшәмәсеннәр ди мондый тырыш керәшен туганнар?! Шул 68 йортлы авылда көтүгә 70ләп терлек йөри, диделәр! Күп җирдә, 200-250 йортлы авылларда көтүнең туктавын ишетеп йөрәгем әрни иде, күңелем күтәрелеп китте.

Авыл халкы чатнатып татарча сөйләшеп, татарча уйлап яши. Күчмә китапханәдәге татарча китаплар да укыла, бөтен җирдә язулар татарча. Урамда очраган балалар, рәхәтләндереп: «Исәнмесез!» – дип дәшеп китә. Рәхәт...

Авылга бер урыс нигез салган, дигән идек. Соңрак та урыслар килеп урнашкан монда. Нәселләре бүген дә билгеле, тик бар да күптән татарлашып беткән инде. Авылда өч-дүрт гаилә мөселман татарлар да бар.

Кешеләр белән аралашкач, бер нәрсә уема килде: мөмкинлегем булса, «бездә эш юк, бетерделәр бит авылны» дип зарланып ятучыларны, автобуска төяп, менә монда экскурсиягә алып килер идем. Чөнки пчеловодлылар кебек матур яшәр өчен дәүләт булышлыгы да, глава кайгыртуы да түгел, бары тик айнык булу һәм матур яшәргә омтылыш кына кирәк. Тырыш Кукмара халкы. Ягы белән тырыш. Чыннан да, башкаларга үрнәк булырлык.

ЯЗЫЛГАНГА КИРЕ КАЙТЫП

Яхшылык җирдә ятмас

Газетабызның 26 гыйнвар санында «Ике катлы агач йорт күз алдында көлгә әйләнде» дигән мәкалә басылган иде. Исегезгә төшерәбез, анда без Казанның Привольный бистәсендә алты кешелек гаиләнең йортлары тулысынча янып бетүе һәм аларның ярдәмгә мохтаҗ булулары турында яздык. Шөкер, янгында зыян күргән гаиләгә ярдәм кулы сузучылар да булды. Чит кеше кайгысына битараф калмаган газета укучылар һәм редакция хезмәткәрләре ярдәме белән, гаилә әгъзаларына шактый кием-салым, көнкүреш кирәк-яраклары, азык-төлек тупланды. Шулай ук акчалата да ярдәм иттеләр. Мәсәлән, Вознесение бистәсендә яшәүче әниле-уллы Рхия һәм Фәрхат Фәйзуллиннар – әнә шундыйлардан.

– «Шәһри Казан» безнең өйгә килә. Әлеге язманы укыгач, әниебезнең бик тә ярдәм итәсе килде аларга. Олы кеше бит, янгында зыян күрүчеләр өчен бик борчылды, – диде безгә Фәрхат әфәнде.

Җыелган барлык ярдәмне без гаилә башлыгы Алексей Кляшевка тапшырдык.

– Ярдәм кулы сузган барлык кешегә дә гаиләм исеменнән тирән ихтирамымны җиткерәм. Һәр кешенең яхшылыгы үзенә меңе белән әйләнеп кайтсын! Булышырга теләк белдерүчеләр бик күп булды. Зур кайгы килмәсә, никадәр яхшы күңелле кешеләр барлыгын белмәгән булыр идек. Кием-салым да җитәрлек бирделәр. Размерлары буенча үзебезгә туры килмәгәннәрен, әрәм булмасын дип, «Альпари» хәйрия фондына тапшырдык, – диде Алексей.

Без аңардан бүгенге хәлләре турында да сораштык.

– Әлегә мәктәпкә якын булган районда фатир арендалап яшибез. Бу мәсьәләдә дә ярдәм итүчеләр булды. Тормыш иптәшемнең дә хәле акрынлап яхшыра бара. (Исегезгә төшерәбез, хуҗабикә нык пешкән иде. – **Авт.**) Иң катлаулысы – документларны торгызу, әлбәттә. Барысы да янып бетте бит. Янгын булган урынны җыештыра башладык. Анда киләчәктә йорт тергезербез дип уйлыйбыз. Бик авыр, әлбәттә, әмма без бары тик яхшыга өметләнәбез. Аякка басачакбыз! – диде ул.

Зәһрә САДЫЙКОВА.

Үлем белән уйнау

Балачактан бер сәер уен истә калган. Беләккә кычыткан белән сугып ярышасың: кем үзен күбрәк чага – шул җиңүче була. Кычытканнан кул кабара да бетә, ә менә бүген балаларның уеннары арасында аяныч төгәлләнә торганнары да барлыкка килә башлады.

Эльвира МОЗАФФАР

ЙӨГЕР ДӘ ҮЛ

Куркыныч уеннарның берсе – «Йөгер дә үл» халык арасында шактый шау-шу уятты. Әлеге уенның шартлары буенча юлда барган машина алдыннан йөгереп узарга кирәк, моны видео, фотога төшереп, бала үзенең «геройлыгы» белән мактана.

Ата-аналарны сак булырга өндәп, уен турында социаль челтәрләрдә шактый кисәтүләр таралды. Дөрес, интернетта бу уенга чакырган сайтлар күзгә чалынмады. «ВКонтакте» социаль челтәрендә әлеге исемдә берничә төркем теркәлгән теркәлүен. Үлемгә кагылышлы цитаталар, хәбәрләр очраса да, уен турында бер сүз юк. Әллә махсус, халыкта коткы тудыру, балаларга бу уенны өйрәтү максатыннан таратылдымы икән мондый хәбәрләр, дип тә уйлап куясың. Начар чир йогышлы була, диләрме әле? Ничек кенә булмасын, аның балалар арасында популярлашу куркынычын булдырмас өчен, вакытында аңлату эшләре алып бару мөһим. Әлеге куркыныч уеннарны кисәтү максатыннан, Татарстанның кайбер мәктәпләрендә, Казанда укытучылар сыйныф сәгатьләре уздыра башлаганнар.

– Бүген Татарстанда «Беги и умри» уены белән бәйле һәлакәт очрагы теркәлмәгән. Балигъ булмаганнар белән эшләү, пропаганда бүлеге, ЮХИДИ хезмәткәрләре ел әйләнәсендә мәктәпләрдә, балалар бакчаларында юл йөрү кагыйдәләрен ныгытуга багышланган дәресләр, профилактика эшләре алып баралар. Хокук саклау органнары өчен дә бу мөһим мәсьәлә булып санала. Кисәтү лекцияләренең нәтиҗәлелеге дә сизелә, – ди Татарстан Эчке эшләр министрлыгының мәгълүмат үзәге өлкән инспекторы Әлфия Сафина.

Социаль челтәрләрдә тарала башлаган тагын бер уен – «Боз һәм тоз». Тәнендә тоз белән бозны кем озаграк тота, шул, имеш, дуслары арасында хөрмәт казана. Бер караганда, боз, тоз зыянсыз кебек, әмма табиблар аңлатуынча, бу элементлар, химик реакциягә кереп, тәнгә тиеп торган урынны сизелерлек өшетә. Әлеге уеннан Алтай, Хабаровск, Красноярск, Кырым кебек төбәкләрдә зыян күрүчеләр теркәлгән.

Балаларның шомлы уеннарыннан чәчләр үрә торырлык. Күптән түгел генә Нижегородск өлкәсендәге «Пеликан» тернәкләндерү үзәгендә булган коточкыч вакыйга күпләрне шаккатырды. Үзәктә имин булмаган гаиләдән балалар тәрбияләнә. Тикшерүләрдән ачыкланганча, фаҗига буласы көнне үсмерләр: «Кем иң матур баланы үтерә ала?» – дип, узара бәхәскә керә. 15 яшьлек кыз, 7 яшьлек кызны мендәр белән каплап үтереп, «батырлык күрсәтә». Менә сиңа уен, менә сиңа балалар!

ӘТИ-ӘНИ УРЫНЫНА – ИНТЕРНЕТ

Соңгы арада үлем белән бәйле уеннар аеруча ешайды кебек. Психологлар, белгечләр моның сәбәбен балаларның күп вакытларын интернетта уздырулары белән бәйләп карый. Үсмерләр социаль челтәрләрдәге төркемнәр аша еш кына кирәкмәгән мәгълүмат алалар. Психотерапевт, психолог **Рамил ГАРИФУЛЛИН**ның исә бу мәсьәләгә үз аңлатмасы:

– Кайбер балалар арасында, билгеле бер сәбәпләр аркасында, әти-әни авторитет булудан туктый, менә шул чакта ул классташлары, дуслары сүзенә, социаль төркемдәге фикерләргә колак сала башлый, – ди ул. – Бу – бик зур бәла. Төркемнәр арасында төрлесе бар: позитив булганнары, суицидка этәргәннәре, секталар. Балалар арасында бәйлелеккә китерә торган тискәре йогынтылы субкультуралар элек тә булган. Хәзер халәтеңә туры килгән төркемне табуы тагын да җиңел, интернет ярдәмгә килә. Депрессиягә бирелгән кешеләр аларга аеруча тиз юлыга. Кемдер интернет уеннар аша адреналин ала. Бу аның эмоцияләрен чыгару, күңел ачу территориясе. Кемдер үзенең суицидка китерә торган уеннарда катнашуыннан ләззәт ала, «сайлап алынган» булуына үзе дә аңламыйча сөенә, мондый кешеләрне «суицидоманнар» дип йөртәләр. Ә кайберәүләр уеннарны читтән күзәтеп торудан рәхәтлек ала. Интернет уеннардан зыян күргән үсмерләр миңа еш ярдәм сорап килә. Шекспирның «Ромео и Джульетта»сын алыйк. Көчле әсәр. Тик төп геройлар белән булган вакыйга кайбер үсмерләргә суицидка этәргеч бирергә мөмкин түгелме? Интернет уеннар белән дә шул ук: әгәр балага вакытында дөрес юл күрсәтелсә, тиешле тәрбия бирелсә, депрессиягә урын калдырылмаса, игътибар җитәрлек булса, рәхәтлек бирә торган хисләрне интернеттагы төркемнәрдән эзләргә сәбәп калдырылмаса, ул һәр нәрсәне объектив кабул итәчәк.

2013 елларда Россиядә мәктәп укучылары арасында социаль челтәрдә «Зәңгәр кит» уены киң таралган иде. Уенда катнашучыларга администратор төрле биремнәр бирә. Аларның күбесе баланың психикасын боза, тән җәрәхәтләре алуга, имгәнүләргә китерә. Уенның соңгы этабы үзүзеңә кул салу белән төгәлләнә. Бүген интернетта «Зәңгәр кит» уены дип җыйсаң, үсмерләргә атап язылган мөрәҗәгать пәйда була. Анда суицидның начар нәрсә икәнлеген аңлатып язганнар, авыр чакта мөрәҗәгать итәр өчен «ышаныч» телефонын да күрсәткәннәр. Бу – суицидны пропагандалаган төркемнәр белән көрәшнең чиратлагы ысулы, күрәсең.

Кечкенәдән безне таныш булмаган кешеләр белән аралашмаска, белмәгән затлардан әйбер алмаска дип өйрәттеләр. Хәзерге заманда бу кагыйдәләргә интернетта кирәкмәгән сайтларга кермәскә, билгесез кешеләр белән язышмаска, интернет уеннар белән сак булырга дип өстәргә кирәктер. Балалар ата-аналарының, якыннарының игътибарын, буш вакытларын үлем белән уйнауга алыштырмасыннар иде.

«Ата-анага бала белән күбрәк аралашырга кирәк»

Татарстанда бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил **Гүзәл УДАЧИНА:**

– Бөтендөнья челтәрендә «Беги и умри» уены 2016 елдан билгеле. Бездә тиешле органнар тискәре йогынты ясый торган һәр контентны ачыклауга, аның белән көрәшә башлый. Бәлки шуңа да хәзер бу уен социаль челтәрләрдә күзгә сирәк чалынадыр. Без, ЮХИДИ белән берлектә, бу уен ни дәрәҗәдә юл һәлакәтләренә китергәнен ачыклау өчен тикшерү уздырабыз. Нәтиҗәләр турында соңрак хәбәр итәрбез. Интернетта суицидка этәрә торган төркемнәр дә җитәрлек. Һәр суицид очрагы буенча җинаять эше ачыла. Республикада интернет уеннар аркасында үз-үзенә кул салу очраклары теркәлмәгән. Ә менә омтылу очраклары бар. Әйтик, былтыр Татарстаннан «җәрәхәтләү» төркеменә (группа порезы) кушылган бер үсмер кыз чак үзенә кул салмый калган иде. Кызганычка, куркыныч тудырган сайтларны бүген ябасың, соңрак алар тагын ачыла. Узган ел Татарстанның барлык мәктәпләрендә бердәй «интернет куркынычсызлыгы» дәресләре узды. Аларны һәр ел уздыру ниятләнелә. Беренче чиратта балалар, аларның әти-әниләре белән эш алып барырга кирәк. Бала үзе яхшыдан яманны аера белергә тиеш. Ата-ана баласы белән мөмкин кадәр күбрәк аралашсын, ике арада ышанычлы мөнәсәбәт урнаштыру мөһим.

Сезнеңчә, интернеттагы үлем уеннары белән ничек көрәшеп була?

Айгөл БАРИЕВА, Татарстанның атказанган артисты:

– Бу уен турында ишеттем. Алла сакласын! Ватсап, социаль челтәрләр аша көн саен яңалык килә. Кайсы чын, кайсы ялган икәнен дә белеп бетереп булмый. Минемчә, баланы интернетка кермә, дип тыюдан файда юк. Кискен тыю, киресенчә, тыелганны татып карауга китерергә мөмкин. Тели икән – өйдә булмаса, башка җирдә бала барыбер интернетка керү җаен таба инде ул. Шуңа да күп нәрсә гаиләдән, тәрбиядән тора. Бездә әтиләре, хәрби буларак, балаларга бу хакта даими аңлатып тора. Шуңа да, шөкер, интернеттагы куркыныч уеннарның ни дәрәҗәдә зыянлы икәнен балалар аңлый, моңа җитди карыйлар.

Рамил МОЗАФФАРОВ, Казан шәһәренең 14нче мәктәбендә укытучы:

– Минемчә, балага бу уеннар турында ачыктан-ачык сөйләргә, әйтергә ярамый. Шөкер, Татарстанда «Беги и умри» уены таралмаган. Әмма бу хакта еш сөйләү, уенның шартларын аңлату балада теләк уятырга мөмкин. Балалардан бигрәк, әти-әниләр белән эшләргә кирәк. Безнең мәктәптә сыйныф җитәкчеләре бу мәсьәләдә кисәтү эшләре алып бара башлады. Балаларга исә читләтеп, гомумиләштереп аңлату мөһим. Әйтик, уенга басым ясау түгел, ә юл йөрү кагыйдәләрен искә төшерү, интернетта кирәксез мәгълүматларның зыянын аңлату нәтиҗәлерәк. Әлбәттә, беренче чиратта, баланы әти-әнисе күзәтергә тиеш. Бала үз эченә бикләнмәгәнме, кемнәр белән аралаша, ниләр турында хыялллана, нинди сайтларга керә? Балага ата-ана һәрчак дөрес юнәлеш күрсәтсен, янәшәсендә булсын иде.

Татарстан прокуратурасының балигъ булмаганнар һәм яшьләр турындагы закон үтәлешен тәэмин итү бүлеге җитәкчесе Азат Хөсәенов әйтүенчә, интернет сайтларның эшчәнлеген туктату буенча республикада ныклы эш алып барыла. Бу максатларда Татарстан прокуратурасы 2015 елда ук мәгълүмати-аналитик комплекс булдырган. Ягъни интернетта хокук бозуларга каршы тору системасы реаль вакытта тыелган контентны ачыкларга, бу хакта Роскомнадзорга хәбәр юлларга һәм судка мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә. Хәзер әлеге система 13 юнәлештә эшли. Наркотиклар, үз-үзеңә кул салу, комарлы уеннар, балалар порнографиясе һәм башкалар белән көрәшне үз эченә алган бу система.

– Әлеге эш башланганнан бирле, наркотикларга кагылышлы тыелган мәгълүмат билгеләре белән 13034 интернет бит табылган. Суицидка кагылышлы – 7734, балалар порнографиясенә кагылышлы 3000 интернет бит булуы ачыкланган. Мондый битләрнең эшчәнлеген туктату өчен, мәгълүматлар тиешле органнарга җиткерелгән, – ди Азат Хөсәенов.

Каным җәл түгел сиңа!

Россиянең мактаулы доноры Казанда яши

Болай дип язганга үзе үпкәләмәс, шөт. Фигаро кебек ул Әнвәр абый: кая барма, ул – шунда. Һәр нәрсәгә үзенең фикере булган, бернигә дә битараф кала белми торган Әнвәр ага Гыйниятуллин күптән түгел янә шаккатырды: 300 (!) тапкыр кан биреп, бик күп гомерләрне саклап калган игелекле җан да икән бит әле ул.

Беренче тапкыр солдатта чагында, Әстерхан өлкәсе Капустин Яр космодромында хезмәт иткәндә донор булырга туры килгән аңа. Авыр яралы хезмәттәшенә кан бирергә бөтен рота теләк белдергәндә, билгеле инде, бер ул гына читтә кала алмый. Ләкин язмышның шаяруы буладырмы бу, әллә инде киләчәкне билгеләвеме – яралы солдатка нәкъ менә аның каны туры килә һәм берәр айдан ул аякка баса. Үз канының тагын кемнеңдер гомерен саклап кала алу мөмкинлеген тою Әнвәрнең күңелендә горурлык уята. Донорлыкның файдасы да тия – аны нәкъ менә шуның өчен туган авылы Питрәч районы Татар Тау Иленә кыска вакытлы ялга җибәрәләр.

Ватан алдындагы бурычын үтәп кайткач та, үзе эшләгән заводта донорлар күнә булганда, ул ике дә уйлап тормый – кан бирә.

– Сәламәт кешегә бернинди авырлыгы да юк. Киресенчә, уңай тәэсир итә бу, биргән кан урынына яңасы ясала. Организм капиллярларыннан башлап чистара, яшәрә. – 40 елдан артык донор булган Әнвәр Гыйниятуллин фикере бу.

Баштарак кан, соңрак плазма да бирә башлый ул. Монысы тагын да файдалырак. Теләсә кайчан әзер кан дигән сүз. Аннары канны ике айга бер тапкыр гына бирергә рөхсәт, ә плазманы аена икешәр бирергә ярый. Кайбер елларда 20шәр тапкыр донор булырга туры килә. Икенче группа уңай резуслы кан аңарда.

Донор булу өчен төп шарт – сәламәт булу. Ә моның өчен дөрес яшәргә кирәк. Әнвәр әфәнде бу хакыйкатьне тиз аңлап алган: тәмәкене ташлавына 20 ел икән инде, аракыны авызына алмавына да шактый булган. Кан басымы космонавтларныкы шикелле, ди. Әле күптән түгел генә, 35 яшьлек ир-атлар белән бертигез нәтиҗә күрсәтеп, ГТО нормалары тапшырып кайткан. 13 ел инде лаеклы ялда булса да (ул автокранчы булып эшләп, 50 яшьтән пенсиягә чыккан), әле бүген дә хезмәттә. Егетләр кебек төз гәүдәле, җиңел сөякле. 63 яшендә булуына карамастан, дельтопланда очар өчен, Бөгелмәгә Карабаш тавына махсус бара.

Беркөнне ул редакциягә шатлыгын уртаклашырга килде. Аңа «Россиянең мактаулы доноры» исемен һәм Россия Федераль медик-биологик агентлыкның «Донор хәрәкәтенә булышлык өчен» («За содействие донорскому движению») медале тапшырганнар. Әнвәр әфәнде әйтүенчә, бу медаль Татарстанда аңарда гына, Россиядә дә андыйлар 47 генә икән.

Хәләл каның белән беркайчан да күрмәгән-белмәгән бөтенләй чит кешенең гомерен саклап калу – фидакарьлек, батырлык, минемчә. Тик Әнвәр әфәнде үзен алай ук батырга санамый.

– Адәм баласы хәленнән килгән кадәр бер-берсенә ярдәм итеп яшәргә тиеш. Акча беләнме, якты йөз, тәмле сүз беләнме – ничек икәнне ул үзе хәл итә. Ә миңа Аллаһы Тәгалә каным белән ярдәм итәрлек исәнлек биргән. Шушы иң зур байлыгыма сөенеп, хатыным Зәйтүнә белән 36 ел аңлашып-санлашып яшибез. Донор булуыма ул да каршы килмәде, рәхмәт. Кызым белән улым да минем белән горурланалар, – ди ул.

БЕЗНЕКЕЛӘРНЕ БЕЛ!

Мөдир бабай

Казан шәһәренең 114нче «Алтын ачкыч» балалар бакчасындагы очрашуда тамашачылар арасында бер абзыйны күргәч тә, башымнан: «Берәр баланың бабасыдыр инде», – дигән уй үтте. Соңрак аның әлеге бакчаның мөдире икәнен белеп бик гаҗәпләндем һәм, билгеле инде, Илгизәр Әхмәтшин белән якыннан аралашасым килде.

Автор фотосы

34 ел буе мәктәп директоры дилбегәсен тарткан стажлы педагог булып чыкты ул. Балык Бистәсе районында да, Казанда да, хәтта өч ел Германиядәге совет мәктәбендә дә биология-химия укытучысы гына түгел, директор булып та эшләргә туры килгән аңа. Биектау районының Кече Клыки авылында элек башлангыч мәктәп кенә булган. Директор аны башта сигезьеллык, аннары урта мәктәп итү өчен бик тырышкан. Ул вакытта Биектау районын җитәкләгән хәзерге Президент Рөстәм Миңнехановның да ярдәме өчен бик рәхмәтле ул.

– Балалар бик күп иде, өч смена укыттык, – дип, ул чакларны искә ала директор. – Аннары ул 118нче мәктәпне Казанның Совет районына бирделәр. Соңрак бинасының иске, шартларының начар, балалар саны аз булуны сәбәп итеп, бөтенләй ябып куйдылар...

Илгизәр әфәнде ир-ат буларак, хисләрен тышка чыгармаса да, күрәм: аңа бу хакта сөйләве авыр. Гомереңне багышлаган мәктәбеңне сүтсеннәр әле! Урынына яңа балалар бакчасы саласылары белгәч кенә бераз тынычлана ул. Нигезенә беренче ташны да үзе салыша. Ә 2014 елда менә шул яңа ачылган бакчага мөдир урынын тәкъдим иткәч, икеләнеп кала. Шулай да тәвәккәлләргә була.

Бүген оныгы Нурвахит белән бергә йөриләр алар бакчага. Баштарак, оныкка кушылып, башка балалар да аңа: «Бабай», – дигәннәр... Ә хәзер аның директор икәнен белеп, тыныша-тырыша, Илгизәр Вахитович, диләр.

Чынлап та, сабыйлар янына килгәч, каушап кала алыптай гәүдәле директор. Баштарак ничектер уңайсызланыбрак та йөри үз эшеннән. Аннары хезмәтенең асылы барыбер шул киләчәк буынны тәрбияләү һәм бу алдагы эшенә карагандан күпкә җаваплырак икәнен дә белеп алгач, бакчасы бер яктан да башкалардан артта калмасын, әти-әниләр дә, сабыйлар да яратсын өчен, алны-ялны белми эшли башлый.

Казанда бердәнбер ир-ат мөдирнең хыяллары да зурдан. Үзе лаеклы ялга чыкканчы, «Алтын ачкыч»ны прогимназия итеп, балаларга башлангыч белемне дә шушында ук бирергә уйлый.

Яшерен-батырын түгел, бүген тәрбиягә ата кулы, ата сүзе җитми. Мәктәпләрдә укытучыларның күбесе – хатын-кыз. Хәтта директор дилбегәсе дә бүген күпчелек нәфис затлар кулында. Ир-атка баш бирергә теләмәгән әниләрнең күбесе бүген баласын ялгыз, атасыз үстерә. Шулай итеп, балага ата тәрбиясе мәктәптә дә, өйдә дә җитми кала. Сыек буынлы, хатынша холыклы «әни малайлары» шулай үсә инде. Ә монда бөтенләй башка сөенечле хәл. Мин әлеге бакчага йөргән балалар өчен шатланып куйдым. Бабайлы булып, аның тәрбиясен алып үсә бит алар! Бәлки, киләчәктә Сухомлинский, Макаренко, Амонашвили, Әхмәтшиннардан үрнәк алып, «бабайлы» бакчалар, «әтиле» мәктәпләрнең саны тагын да артыр.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

КИҢӘШ САНДЫГЫ

АШ БУЛСЫН

Рәфилә Шәмсетдиновадан алмалы ватрушка

400 гр он, 150 гр маргарин яки сыер мае, 150 гр шикәр комы, 1 йомырка, 250 гр эремчек, 1 зур алма, 1 чәй кашыгы корица, 1/3 чәй кашыгы сода

Өй температурасында эрегән маргарин яки сыер маен он белән уарга. Шикәр комының 100 граммын, аш серкәсе белән сүндерелгән сода һәм ярты йомырка белән кушып, онга салырга. Камыр уылган валчык сыман була. Эчлек өчен эремчек, 50 гр шикәр комы, ярты йомырканы бергә кушарга. Камырның бер өлешен майланган табаның аскы өлешенә җәясе, анннары – эремчекле эчлекне, аның өстенә, яссырак итеп, туралган алманы. Аңа аз гына шикәр комы һәм корица сибәргә һәм өстенә калган камырны җәясе була. Өстен тигезләп чыгып, 220 градуслы мичтә 20 минут пешерәсе.

СӘЛАМӘТЛЕК

Организмнан артык тозларны чыгару өчен, иртән бер уч йөзем ашагыз. Аннары ике сәгать буена бернәрсә эчмәскә һәм ашамаска. Икенче көнне бер аш кашыгы бал ашагыз. Шулай ук ике сәгать ашамый-эчми торыгыз. Берәр килограмм йөзем белән балны шулай чиратлаштырып ашап бетергәч кенә тәнәфес ясагыз.

БЕЛЕП ТОР!

Клумба матур килеп чыксын өчен, бер еллык чәчәкләрне түбәндәге тәртиптә утыртып карарга киңәш итәбез.

1) канна – 3 данә
2) бегония гарцелис – 15 данә
3) бакра гөл (петуния) – 10 данә
4) арыслан авызы (львиный зев) – 6 данә
5) бәрхет гөл (бархатцы) – 10 данә
6) алиссум – 10 данә
7) агератум – 10 данә
8) кәя чәчәге (пиретрум) 8 данә

Клумба диаметры – 1,3 метр



КЫЗЫКЛЫ ИДЕЯ

Почта әрҗәндә хат бар

БАКЧАЧЫГА

✓ Бакчачыларның төп хатасы – кыяр белән помидорны бер теплицага утыртуда. Аларга иксенә ике төрле температура кирәк һәм һава дымлылыгына карата да таләпләре төрле. Теплицага кыяр утыртырга җыенсагыз, аның иртә өлгерә торган сортларын сайлагыз. Апрельдә һәм июнь ахырында утыртсагыз, бер сезонда ике уңыш алып була. Теплица җылытыла торган булмаса да, иртә язда анда редис, кыякка суган, укроп, петрушка утырта аласыз. Дачалары булганнар көз көне бакчаларына еш йөри алмаса, анда кыяр яки помидор уңышын җыеп алгач бушап калган урынга солы, арыш кебек бөртекле культуралар чәчегез. Алар жирне туклыклы матдәләр белән баета.

✓ Авыру крыжовникны кайнар су сибеп сәламәтләндерегез. Лейкага кайнар су тутырып, куаклар өстенә тиз генә сибегез. Әлеге эшне апрель аенда эшләргә була.

✓ Алмагач белән чияне янәшә утыртмагыз, аларның тамырлары бер-берсенә зыян гына китерә.

✓ Алмагач төбенә әрем яки гөлбадран (пижма) утыртсагыз, алар аны җимеш корткычтан (плодожорка) саклар.

✓ Кыярга үсемлек бетләре иләлшсә (тля), көл өстенә кайнар су салып, шуны кыяр өстенә сибегез.

✓ Кәбестә күбәләге календула һәм помидор ботагы исен яратмый. Димәк, кәбестә рәтләре арасына шуларны утыртырга кирәк.

✓ Кәбестәдәге күбәләк личинкаларыннан котылу өчен, нарат һәм чыршы ылысларын иттарткыч аша чыгарып, кәбестәнең аскы яфракларына һәм әйләнә-тирәсенә сибеп чыгыгыз.

✓ Бәрәңгегә суны ул чәчәк аткач кына сибегез, бүлбеләре тизрәк формалаша. Чәчәк атканчы су сибүнең әллә ни нәтиҗәсе юк.

ИР-АТЛАРГА

ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР

- Утырып эшләсәгез, һәр сәгать саен өч минут гимнастика ясап алыгыз. Аны урындыктан тормыйча гына да эшләп була.
- Юкка-барга борчылмагыз.
- Беркем белән дә ачуланышмагыз.
- Суны күп итеп эчәргә тырышыгыз.
- Кимендә сигез сәгать йоклагыз.
- Мунча кирәгез.
- Йога белән шөгыльләнегез.
- Табиблардан курыкмагыз, һәрдаим тикшеренеп торыгыз.
- Сыйфатлы ризык кына ашагыз.
- Туклануга акча жәлләмәгез.
- Ашаган саен, авызыгызны җылы су белән чайкатыгыз.
- Телевизорны озак карамагыз.
- Җәяү йөрегез.
- Тәмәке тартуны ташлагыз.

МӘЛЕНӘ – ӘМӘЛЕ

Эшне тизләтәбез

Голубцы (кәбестә яфрагына төреп пешерелгән итле дөге) өчен кәбестә яфрагын, гадәттә, кайнаган суда пешереп алып, суынганын көтеп торабыз. Ә аның тиз генә әзерләү ысулы бар икән бит. Беренчедән, кәбестәнең зур, әмма юка яфраклысын сайлагыз. Аны юып, өстәге берничә яфрагын һәм күчәнен кисеп алабыз да микродулкынлы мичкә куябыз. 1,5-2 кг кәбестәне 900 Вт лы режимга якынча 12 минутка куярга кирәк. Аннан алгач, салкын су астында яфракларын җайлап кына салдырабыз.

Микродулкынлы мичне бик күп максатларда кулланырга була. Әйтик, искергән ипине бер минут җылытып алсагыз, ул мичтән яңа гына пешеп чыккан кебек була. Әфлисун кабыгын да мичтә тиз генә киптереп алырга мөмкин. Әфлисун согы яхшы сыгылсын өчен, аны берничә минут мичтә тотып алыгыз. Шикәрләнгән балны да аның ярдәмендә эретеп була.

ХАТЫН-КЫЗЛАРГА

Кер юу машинасында пуховикны ничек итеп дөрес юарга? Кыш көнендә иң актуаль сорауларның берсе бу. Пуховикны юар алдыннан, молниясен каптырып, эчке ягын әйләндереп куегыз. Әлеге өс киемен үзен генә юыгыз. Чын пуховиктан кер порошогы беркайчан да юылып бетми. Шуңа да сыек порошок кулланырга киңәш итәбез. Йоннары укмашмасын өчен, кер юу машинасында дүрт теннис шарын да әйләндерегез. Суның температурасы түбән булсын. Кимендә өч тапкыр чайкатыгыз. Пуховикны балконда киптерергә кирәк. Җылыту приборлары өстенә куя күрмәгез.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА әзерләде.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

ТАНКИСТ

Казан танк училищесы мәйданына җиңел генә эләгеп булмый. Ул дәүләт эчендәге дәүләт кебек үз кануннарына буйсынып, үз таләпләре белән яши. Шулай да Ватанны саклаучылар көне алдыннан танк гаскәрләре өчен офицерлар тәрбияләүче Россиядәге бердәнбер уку йорты белән танышу җае чыкты.

Алисә САБИРОВА

ИҢ-ИҢНӘР КИРӘК

Бирелә бөтен ил буенча җыелган 4 меңгә якын кеше белем ала. Офицерларның күбесе хәрби тормышны инде мәктәп бусагасын атлап кергәнче сайлап куйган була. Шуңа да конкурс зур: бер урынга якынча биш-алты кеше туры килә.

– Училищега 17 яшьтән укырга керергә ярый. Гади мәктәпләрдән дә, Суворов, кадет мәктәпләреннән дә килиләр. Ләкин без бөтен кешегә дә бер үк төрле таләпләр куябыз. Киләчәктә алар – Россия армиясен җитәкләүче кешеләр, шуңа да иң-иңнәрен генә сайлап алабыз. Укырга кергән егетләр арасында армия хезмәтеннән кайтканнар да бар, – диде шәхси состав белән эш итү буенча училище җитәкчесе урынбасары Владимир Попов.

Егетләрнең училищедагы беренче елы чакыру буенча армиядә хезмәт итүгә тиң булса, икенче курстан алар Россия Саклану министрлыгы белән контракт төзи. Укуларын тәмамлагач, контракт тагын биш елга озынайтыла. Офицерларны илнең теләсә кайсы ноктасына җибәрергә мөмкиннәр. Училищены «бишле» билгесенә генә тәмамлаган, уку барышында үзен бары тик яхшы яктан гына күрсәткән егетләргә исә хезмәт итәсе частьларын үзләренә сайларга мөмкинлек бирәләр.

Уку йортында хәрби династияләр күп. IV курста укучы Михаил Лагочев Ставрополь шәһәреннән килгән.

– Казанга мин сигез ел элек күчендем. Башта Суворов училищесында белем алдым, соңыннан танк училищесына кердем. 1969 елда әлеге уку йортын әти дә тәмамлаган иде. Мин дә аның эзеннән киттем, – ди яшь офицер.

Суворов училищесын ул гел «биш»кә генә тәмамлый. Бу уку йортында да «алтын»га бара. Суворовчылар мәктәбен узган егет буларак, укырга керү җиңел бирелә. Укырга кергәндә, 18 тапкыр турникта күтәрелә, 100 метрны – 12,2 секундта, 3 чакрым араны 11 минутта йөгереп үтә. Егеткә мини футбол буенча спорт мастеры булуы да ярдәм итә. Саклану министрлыгы спорт белән шөгыльләнгән егетләрне һәр яктан хуплый икән.

– Хәзерге вакытта миңа лейтенант дәрәҗәсен бирүләрен көтәм. Укып бетергәч тә, теләсә кайсы частьне сайлый алам, ләкин бу җаваплы эшне язмышыма тапшырам. Кая җибәрүләре мөһим түгел, иң мөһиме – минем файдам тия торган җир булсын, – ди егет.

БУЛАЧАК МИНИСТР

Нинди генә курсанттан сорама, иң истә калган мизгелләре буларак, Җиңү парадында катнашу һәм кулга корал тоту, дип җавап бирә алар.

– Танкта бер тапкыр да йөрмәгән, атып карамаган офицер чын мәгънәсендә үзен танкист дип әйтә алмый әле. Күз алдыгызга китерегез, 46 тонналы машина син ни кушасың, шуны эшли. Бу искиткеч хисләр. Училище техникага, армиягә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләде. Мин инде үземне хәрби тормыштан башка күз алдына да китермим. Илгә хезмәт итү минем каныма сеңгән, бу минем бурыч, – ди Михаил.

Генерал булырга теләмәгән солдат – начар солдат, диләр. Аның максатлары тагын да югарырак.

– Генерал исеме белән генә чикләнмәячәкмен. Хыялым – саклану министры булу. Министр Сергей Шойгу белән очрашып сөйләшкән бар. Мин аңардан үрнәк алырга тырышам, – диде егет.

Михаил бүген үзе взвод җитәкли. Аның кул астындагы егетләр белән дә таныштык. Өч катлы казармада 123 кеше яши. Бирелә искиткеч чиста. Офицерларның ял бүлмәсе түрендә үк зур пианино тора. Курсантларның 80 проценты пианино белән гитарада уйный белә икән. Компьютер уеннарын исә шахмат белән шашка алыштыра. Офицерларның үзенчәлекле хоббилары да бар: алар, ярыша-ярыша, аквариум тота. Шуңа да казарманың һәм почмагында төрледән-төрле балыклар белән аквариумнар. Көн саен телефоннан якыннары белән 30 минут сөйләшергә мөмкин.

– «Увольнение» вакытында киногa йөрибез, төрле чараларда катнашабыз. Курсант өчен Казанның бөтен ишекләре дә ачык. Без хәтта шәһәр бассейннарына бушка йөрибез. Без бит дәүләт серен саклыйбыз, шуңа күрә телефоннардан еш куллана алмыйбыз аңлашыла да. Гомумән, уку йорты төрле яктан үсү өчен мөмкинлек биргән. Граждан тормышындагы егетләр һәм кызлар телефоннарыннан аерыла алмый, ә без чын тормыш белән яшибез, – ди егетләр.

Офицерларга иртә белән торып урын-җирне җыештыру, форточканы ачып бүлмәне җилләтү һәм спорт киемен кию өчен – ике минут, юыну өчен – ун, физкультурага 40 минут вакыт бирелә. Алар көн саен 5-7 чакрымга йөгерергә тиеш. Бәлки шуңадыр да хәрбиләр бар яктан да төгәллекне ярата.

> **Бөек Ватан сугышы вакытында училище 5000гә якын танкчы әзерли. Шуларның 39ы Советлар Союзы герое исеме ала.**

КЫЗЛАР ЭШЕ ТҮГЕЛ

Алар укыганда ук танклар белән эш итә. Уку йорты территориясендә чын хәрби техника тора. Җир өстеннән йөри торганнардан тыш, суда йөзә һәм су астыннан йөри торган танклар да бар монда. Танклар тыштан шулкадәр зур булып күренсә дә, эчкә кергәч, артык хәрәкәтләргә урын калмый икән. Командир, механик, наводчикның – һәрберсенең үз урыны. Алар бер-берсе белән махсус элемтә аша аралаша. Танк әйләнә калса, астында запас чыгу юлы бар.

– Танкны сүтеп җыю – егетләрнең иң яраткан шөгыле. Техниканы яратмаган кеше бездә укый алмый, – ди техниканы ремонтлау һәм куллану кафедрасы профессоры Марс Әхтәриев.

Тормышта төрле очрак булырга мөмкин, укуын тәмамлапта, хәрби хезмәткә китә алмаган егетләр бирелә персонал белән идарә итүче белгечләрен алып чыга.

Егетләр генә түгел, күп кенә кызларның да хыялы бу танк училищесы. Тик аларны алмыйлар.

– Безнең хезмәт кызлар өчен түгел. Физик яктан бик авыр эш бу. Затворның клины гына да 70 кг, аккумулятор да шуның кадәр авырлыкта. Снярядларның берсе 20шәр кило, – ди Владимир Попов.

Ләкин Казан танк училищесын тәмамлаган хатын-кыз бар икән тарихта. Ул – танылган сәясәтче, революционер Сергей Кировның кызы Евгения Кострикова. 1944 елда ул танк училищесында кыска вакытлы курсларны бары тик «бишле»гә генә тәмамлап, Т-34 танкында командир булып хезмәт итә. Аның танкы Берлинга кадәр барып җитә.

Ничек укырга керергә?

1. БДИ: математика (төп юнәлеш), рус теле, җәмгыять белеме буенча.
2. Училищега укырга керергә теләгән егетнең сәламәтлеге «А» категориясендә булырга тиеш.
3. Физик әзерлек: кыска (100 метр) һәм озын (3 чакрым) дистанциягә йөгерү, турниктан күтәрелү.
4. Психологик тест.
5. Укырга кергән егетләргә хәрби һәм дәүләт серләре ачыла. Шуңа да ата-аналарның, якын туганнарның нинди дә булса җинаять эшенә тартылмаулары, закон бозмаулары мөһим.

Стипендия:

I курста – 2 мең сум (каникул вакытында өйгә кайтып килү өчен юл бәясен хөкүмәт түли).

II-IV курста – 15-20 мең.

Кыю кызлар

«Өч тапкыр кияүгә чыга яздым»

Армиядә хезмәт итү хатын-кыз эше түгел дип кем әйтә? Узган елны гына да Татарстаннан контракт буенча 11 хатын-кыз армиягә киткән. Минзәлә районыннан Анастасия Асанованың Көньяк Осетиядә хезмәт итүенә тиздән өч ел тула. Башта өч елга гына дип уйлаган булса, шушы көннәрдә ул контрактның биш елга кадәр озайткан. Анастасия Асанова Цхинвал дигән хәрби шәһәрчектә урнашкан разведка батальонында санитар инструктор булып хезмәт итә. Армиягә бару теләге исә Минзәлә медицина училищесында укыганда барлыкка килә.

– Сыйныф җитәкчебез безнең райоңнан ике кызның армиягә китүен әйткәч, минем дә барасым килде. Хәрби комиссариатка барып сорашып-белешеп тә кайттым. Документларны барып тапшырдым. Армиягә аласыларына ышанып та бетмәгән идем, әмма миңа шалтыраттылар. Баштарак чит җиргә, бер белмәгән кешеләр янына китү авыррак булды. Тиз ияләштем анысы, якташлар да табылды. Аннары миңа Осетиянең табигате бик ошый. Бирегә килгәнемә үкенмим, әле ярый килгәнмен, дим. Мондагы режим да, физик чыныгу да ошый, һәр яктан тотрыклылык сизәм, хезмәт хакым да әйбәт, аена 43 мең сум акча алам. Продуктлар да бирәләр, бушка ашим. Бүлмәдәшләремнең берсе – Владикавказдан, икенчесе – Карелиядән. Юлга льготалар бар. Контрактны сузган очракта фатир, шифаханәгә юллама да бирәләр дип ишеттем.

– Армиядә романтикага урын бармы?

– Романтика җитәрлек! Өч тапкыр кияүгә чыга яздым. Әле иртәрәк дип, бу уйдан кире кайттым. Шәһәребез кечкенә, шуңа да эштән буш вакытта Владикавказга барып кайтабыз. Анда кино карыйбыз, клубларга барабыз. Китапханәгә дә, спорт залына да йөрибез. Тиздән бассейн да ачылачак.

– Эшең авыр түгелме?

– Күнектем инде. Иртәнге сигездә сафка тезелеп басабыз, гимн җырлыйбыз. Аннары казармага барып, журналларны тикшерәм, авырулар булу-булмавы белән кызыксынам. Полигонга чыккан вакытлар да була. Госпитальдә дежур торам. Укулар оештырыла, ярты ел саен физик әзерлекне тикшерәләр, чыныгу курсларын (курсы выживания) үттем. Анысы бигрәк авыр булды, әмма күп нәрсәгә өйрәндем. Ахырга таба ошый да башлады. Командировкаларга да еш йөрибез.

– Ял бирәләрме соң?

– 45 көн ял һәм алты тәүлек юлга бирелә. Минзәләгә әти-әнием янына кайтам. Хезмәт иткән шәһәремне, дусларымны ялдан сагынып киләм.

Тырыш кешене кайда да күрәләр, өч ел эчендә Анастасиянең рәхмәт хатлары шактый җыелган, хәтта өч медале дә бар.

«Монда хатын-кызларга хөрмәт зур»

Азнакайда да яши икән батыр кызлар. Тумышы белән шул районнан булган 20 яшьлек Миләүшә Сәетова хезмәт итәргә ире Флорид белән киткән. Алар Көньяк Сахалинда яшиләр. Миләүшә Бөгелмә медицина училищесын тәмамлаган. Армиядә танк батальонында санитар инструктор булып эшли. Ире Флорид исә – радиотелефонист.

– Армиядә контракт буенча хезмәт итәбез. Монда килгәнгә әле өч кенә ай. Икәү булгач, ияләшү авыр булмады. Бирегә икебез бер сүздә булып килдек. Өйләнешкәнебезгә сигез генә ай, яшь гаилә булгач, фатир проблемасы килеп туа. Армиядә контракт буенча хезмәт итүчеләргә күп өстенлекләр каралган, хезмәт хакы да югары, пенсиягә иртә чыгасың, фатир сатып алганда да льготлар каралган. Әмма боларга кызыгып кына хезмәт итеп булмый, армия сиңа ошарга тиеш. Хатын-кызларны монда бик хөрмәт итәләр. Барысы да читтән килгән кешеләр булганга мы икән, мондагылар үзара бик дус, – ди Миләүшә.

«Армия түзем булырга өйрәтә»

Әлмәт районының Габдрахман авылы кызы Гөлназ Гайнанова Мурманск өлкәсенең Алаку́ртти бистәсендә хезмәт итә. Бирегә килүенә ике генә ай булган. Әлегә санитар булып эшли, тиздән анестезиолог вазифасына керешәчәк. Армиягә киткәнче, ул ун ел Әлмәттә «Татнефть» медицина-санитар частенда реанимация анестезиологы булып эшләгән.

– Армия балачак хыялым түгел. Тормыш үзе мәҗбүр итте, монда килүем чарасызлыктан дип әйтергә була. Элеккеге эштә хезмәт хакы кимеде. Ирем кредитлар, әҗәтләргә батырып чыгып китте. 8 һәм 12 яшьлек ике балам белән ялгыз калдым. Иң беренче чиратта акча мәсьәләсен хәл итәргә кирәк иде, яхшылап уйлаганнан соң, өч елга контракт төзеп, Мурманскига киттем. Хезмәт хакым күпкә яхшырак монда. Әлбәттә, балаларымны сагынам, алар әти-әнием белән яши. Үземнең яныма да алып киләсем килә, бер ияләшкән мәктәпләрендә укысыннар инде дип тә уйлыйм. Аннары монда табигать шартларына ияләшү дә авыррак булачак, – ди ул.

Гөлназ әлегә бүлмә арендалап тора, шушы араларда фатир ачкычларын тапшырырга тиешләр икән.

– Беренче көннәрне авыр булды, хәзер инде ияләштем, – ди ул. – Хатын-кызларны армиядә дип элек күз алдына да китерә алмый идем, бирeдә алар бик күп икән. Безнең ротада гына да 20дән артык кыз. Сафка басулар, йөгерүләр – барысы да бар. Гел спорт ярышлары уздыралар, анда катнашам. Март аенда «курсы выживания» булачак. Граната ыргытырга да, танк астында калырга да, окоп казырга да өйрәнәчәкбез. Хәрби хезмәттә сәламәтлегең яхшы булу, ихтыяр көчең зур, түзем-чыдам булу кирәк, әлбәттә.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

ВАТАН САГЫНДА

«Илне без сакламасак, кем сакласын?!»

Өч улы да Ватан сагында торучы Сания апа белән Шамил абый Нигъмәтҗановларның һәр шимбә иртәсе тәрәзәгә карап башлана. Ә өйдә уллары яраткан өчпочмак, кыстыбый, аш исе таралган. Һичшиксез, кайсы булса да кайтырга тиеш бит бүген.

Алисә САБИРОВА,
Яшел Үзән

– Аларның телләре дә «Служу Советскому Союзу» дип ачылды. Үз юлларын үзләре сайладылар, без каршы килмәдек, – дип елмая әниләре.

Олы уллары Зөфәр кечкенә вакыттан ук, хәрби булам, дип йөргән. Аңа төпчекләре Салават та кушылган. Абыйлы-энеле бертуганнар икесе дә Чистяков исемендәге Казан югары артиллерия училищесын тәмамлый. Төпчекләре Зөлфәткә дә хәрби тормыш ят түгел: автотранспорт техникумын тәмамлагач, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институтында белем ала. Хәзерге вакытта ЮХИДИ хезмәткәре.

– Безгә әти һәрвакыт үрнәк булды. Ике ел Ерак Көнчыгышта хезмәт иткәннән соң, аңа командирлары Казан танк училищесында белем алырга тәкъдим иткән. Ләкин ул бу хыялын тормышка ашыра алмаган. Әти, төпчек бала булмаса да, әти-әнисенә терәк-таяныч булып төп йортта калган. Әтинең хыялын без тормышка ашырдык. Аннан соң

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

кемгә дә булса илне сакларга кирәк бит. Без сакламасак, кем сакласын?! – ди олы уллары Зөфәр.

Училищены тәмамлагач, ул биш ел Екатеринбург шәһәрендә хезмәт итә. Хатыны да аның артыннан берсүзсез иярә. «Декабрист хатыннары кебек, кая китсәм, шунда барды», – ди гаилә башлыгы. Бүгенге көндә алар Казанда яши, ике кыз бала тәрбияләп үстерәләр. Уртанчылары Зөлфәт тә тормышлы, уллары бар.

Салаватның исә бүген дә хәрби операцияләрдән кайтып кергәне юк. Хәзерге вакытта ул Финляндия чигендә урнашкан Мурманск шәһәрендә хезмәт итә. Әле узган ел гына гаилә корган.

– Башка кызлар, армиядән кит, дип әйтәләр иде. Алия исә, син кая – мин шунда, дип, берсүзсез риза булды. Гомумән, үз кызларым булмаса да, киленнәрдән уңдым мин. Аларны бик яратам, – ди Сания апа.

Күрсәткән батырлыклары өчен Салават Нигъмәтҗанов II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале һәм III дәрәҗә «Батырлык ордены» белән бүләкләнә. Моннан тыш, егетнең төрле өлкәдә кылган батырлыклары өчен бирелгән өч медале бар. Ләкин кайсы өлкәләрдә хезмәт итүе хәрби сер булып сакланырга тиеш.

Егетләр мәктәптә дә, училищеда да яхшы укый. Зөлфәт белән Зөфәр мәктәпне гел «бишле»гә генә тәмамлыйлар. Спорт белән актив шөгыльләнәләр. Өйдә дә нык куллы хуҗалар.

– Зөфәр бөтен илнең президентларын таный иде. Мәктәпкә кергәнче үк, бөтен сәяси тормышны белде. Без көн-төн эштә, өйрәтеп утырырга вакыт булмады, үзе кызыксынды, телевизордан өйрәнде, – ди әтиләре.

– Эш белән чыныгып үскән балалар алар. Кояш чыкканчы йоклап ята алмадылар. Әтиләре ул яктан бик таләпчән булды, – ди әниләре.

Ерак сәфәргә эшкә киткәнче, егетләр мәчеткә сәдака биреп, әти-әнисенең хәер-фатихасын ала. Бу – гаиләнең язылмаган кануны.

Гомер буйлап барам...

Әңгәмәнең тулы варианты www.shahrikazan.com сайтында

Айдар Галимов гаилә, иҗат һәм мәхәббәт турында

КУНАК БҮЛМӘСЕ

Айдар тормышта да, сәхнәдә дә бер кеше. Һәрвакыт ихлас, кешелекле, кечелекле. Продюсерлар уйлап чыгарган образ түгел, ничек бар шундый шул Айдар!

– Беренче сорау, әлбәттә, юбилеегызга кагылышлы, Айдар. 50 яшегезне ничек каршылыйсыз? Эшлисе эшләр эшләнгән, дисезме, әллә: «Бар да алда әле», – дип яшисезме?

– 50 яшь ул – тормышның бер этабы, бер чиге. Гомеремдә 50 яшькә җитеп килгән күп кешеләрне очратканым булды. Аларның әлеге датаны ничектер куркыбрак, кайгырыбрак каршы алганын да күзәткәнем бар иде. Әмма мин әллә ни кайгырмыйм, борчылмыйм, бу көнне ниндидер зур бәйрәм итеп кötәм. Гаиләм өчен дә ул зур вакыйга. Әти-әнием өчен дә. Бәлки тамашачыларым, райондашларым, сайлаучыларым өчендер дә... Башкалар миннән дә ныграк әзерләнә диган фикергә килдем. Ә үзем шуңа читтән карап шатланып торам.

Миңа калса, кеше 100 яшькә җитсә дә, «Бар да алда әле», – дип яши, «Бар эшем дә эшләнеп бетте, тик кенә утырыйм әле», – дип әйтмидер. Шәхсән миңа килгәндә, әле бар да башлана гына! Әлбәттә, күп эшләр эшләнгән. Кайчак уйлыйм: бәлки күбрәк тә эшлисе булгандыр, бәлки вакытымны дөрес булмәгәнмендер? Бәлки энергиямне башка, кирәкмәгән эшкә күбрәк юнәлткәнмендер? Шундый уйлар башка керә.

– Ә мәхәббәтне хәзер ничек тоемлыйсыз? Еллар үтү белән, хатыныгызга караш үзгәрдеме?

– Минем язмышым маңгаема язылган булгандыр. Зилә белән безне Уфа автотранспорт техникумы таныштырды. Очраклы очрашу булмый. Зилә мине армиягә озатты һәм ике елдан каршы алды. Популярлыкка ирешкәч кенә тормышымда пәйда булмады, ә иң баштан ул минем янымда.

Нәрсә ул мәхәббәт? Ул – җан белән җан арасындагы аңлатып булмый торган тойгы, аңа дөрес аңлатманы Ходай Тәгалә үзе генә бирә аладыр. Ә яши-яши караш кына түгел, тойгылар да үзгәрә икән. Кешене бит башта бер төрле күрәсең, аның төс-кыяфәтенә, киеменә игътибар итәсең, соңыннан гына эчке дөньясына керәсең. Ә кешенең күңелен белеп бетерер өчен күп еллар кирәк. Зилә белән күпме бергә яшибез – аны шулкадәр ачам һәм көннән-көн ныграк гашыйк булам, тагы да тирәнрәк ихтирам итәм. Бүген без дуслар буларак үсеп җиттек, ә дуслар булу – зур нәрсә ул.

Җырчы булу, депутатлык эше белән шөгыльләнү гаиләмә зур йогынты ясый. Кызганычка, якыннарыма тиешле игътибарны бүлә алмыйм. Бу яктан гаиләмә җиңел түгел. Бергәләп ике атнага шифаханәгә барып ял итү – күптәнге хыялым.

Гаиләдә күп нәрсә ир-аттан торса да, балалар тәрбияләүдә мөһим рольне хатын-кыз уйный. Еракта булган вакытымда да балалар минем якында икәнемне сизеп торды. Аларның миңа булган уңай мөнәсәбәте – Зиләнең дөрес тәрбиясе. Ул аларга иҗатымның, эшемнең халык, гаилә өчен ниндиди мөһим булганын акыллы итеп аңлата алды.

– Сездә кем баш, кем – муен?

– Гаиләдә дә мин – зур җитәкче. Бөтен әйберне контрольдә тотарга кирәк. Әлбәттә, мин – баш, Зилә – муен. Ул шулай булырга да тиеш. Ә башны дөрес якка борырга Зиләнең дә киңәшләре кирәк.

– Татар эстрадасы җырчылары арасында сез беренчеләрдән булып үз рәсми сайтыгызны булдырдыгыз. Хәзер социаль челтәрләр заманы, ә сез һаман бер җирдә дә теркәлмәгән.

– Интернет ул, чамасы белән, әйбәт әйбер. Аны кирәк мәгънәдә куллану яхшы. Мәсәлән, безгә электрон почта аша композиторлар яңа җырлар җибәрәләр. Аранжировкаларны шул рәвешле эшлибез. Ә элек моның өчен күпме ара үтеп, вакыт сарыф итәргә кирәк иде. Тыңлаучылар белән дә араларны интернет якынайта. Аларның киңәшләрен тотабыз, фикерләренә, тәнкыйтьләренә колак салабыз.

Ә инде инстаграм кебек челтәрләрне чир, вирус кебек кабул итәм. Әйе, анда кемнәрдер матур итеп үз битен алып бара: минем кызлар да, коллегалар да. Гаепләмим: аларның үз эше, моңа карата үз карашы. Ә чир дигәне, беләсезме, нәрсәдән? Менә кайчак синең яныңа берәү килә дә, исәнләшми-күрешми, ә фотога төшерә башлый, селфи ясый. Бу нәрсә? Чир түгелмени? Куркыныч нәрсә бит. Димәк, ул виртуаль дөньяда яши.

Интернет – йөгәнсез ат бит, аны берничек тә контрольдә тотып булмый. «Мин бер социаль челтәрдә дә утырмыйм», – дип рәсми белдерү ясадым, әмма барыбер клоннар бар һәм халык аларга ышана.

– «Моңнар кайтсын авылга», «Елама, ярсыма», «Кызыл розалар» – мега популяр хитларыгыз. Ә бүгенге җырлардан кайсылары алар рәтенә кертер идегез?

– «Син минем җанымның яртысы». Әмма ул бүгенге җыр түгел, элеккеге хит булып саналадыр. Әлеге концерт программаннан «Хыяллардан бәхет эзлибез», «Мәхәббәтем минем» җырлары күңелемә якын. Әмма барыбер бөтен җыр да, беренче еллардагы кебек, популяр булып яңгырамаячак. Сәбәпләр төрле. Бәлки ул заманда җиңелрәк булгандыр. Башкаручыларның саны моның кадәр булмагандыр. Шунысы кызык: ул заманда «чыккан» җырлар әле дә яңгырый бит. «Елама, ярсыма»ны Радик җырлый, тамашачының күбесе бу җырны мин башкарганны белми дә, ә яңа җыр дип кабул итә.

– Радик турында сүз чыккач, киләсе сорауны аңа бәйлисе килә. Сезнең күзлектән, яшь җырчының популярлык сере нәрсәдә?

– Бу сорауга җавап табар өчен, Радикның концертына бардым. Беренчедән, ул үз хезмәтен бик ярата, тырышып эшли. Фанатларын, тамашачыларын ярата. Мин моны концертта күрдем, тойдым. Тавышында ниндидер моң, сагыш бар, һәм җыры күңелгә барып җитә. Әллә нинди көчле, дөрес тавышлар бар, әмма күңел кылларын тибрәтә алмыйлар. Ә Радикта харизма бар. Тырыш егет. Ул – үз заманының феномены.

– Ватанны саклаучылар көне алдыннан армия турында сүз кузгатмый булмый. Хәрби хезмәт елларын искә алыйк әле.

– 1986-1988нче елларда Каунас һава-десант гаскәрләре дивизиясендә хезмәт иттем. Безнең заманда – ике, ә хәрби хезмәт флотында өч ел хезмәт итү иде. Тик ул вакыт та җитми кебек иде. Заманы башка иде бит. Үзебез: «Әфганстанга безне дә алыгыз», – дип гариза яза идек.

Ике ел хезмәт эчендә мин бөтенләй башка кеше булып үзгәреп кайттым. Карашлар үзгәрде, чыныгу алдым, тәҗрибә тупланды. Җитди адымнарга әзер булып кайттым.

Әлбәттә, ул елларда да армиядән качып калу мөмкинлеге бар иде, тик андый уй башка керел тә чыкмады. Өченче сыйныфта укыганда, кулым сынган иде. Бик озак төзәлде. Әле дә үзен сиздерә. Бавнда уйнаганда, ул кул тизрәк арый. Әгәр дә бу сыну турында әйткән булсам, һава-десант гаскәрләре дивизиясенә алмаслар иде. «Сынган урыннарыгыз бармы?» – дип кат-кат сорадылар.

Армия турында сүз чыккач, мин гел беренче тапкыр парашют белән сикерүем турында сөйлим. Анда бит сорап та тормыйлар, тибеп дигәндәй төшерделәр. Сикердем, барыбыз да һавада чылбыр кебек тезелеп калдык. Шул картина әле хәзер дә күз алдымда. Һавада асылынып калгандай булдык. Шулчак, үзем дә сизмәстән, «Керкәле таулары»н җырлый башладым. Ә инде башка бер җилле көнне парашют читкә алып китте. Литваның иген басуына төштем. Борылсам, каршыда бер сыер миңа карап күшәп тора. «Син монда нәрсә эшләп йөрисең?» дигәндәй иде чырае. Ул сыерны мәңге онытмыйм.

– Узган ел да сезнең өчен мөһим вакыйгаларга бай булды. Иҗатыгызга 25 яшь тулды. Оныгыз София туды.

– Оныгым тугач, бер танышымны очраттым. «Хәзер депутат статусың да төшеп кала, син хәзер – картәтәй», – диде. Чынлап та, кадерле статус икән ул. София туганын хәбәр иткәндә, мин стадионда футбол карый идем. Шулкадәр сөендем, 0:3кә җиңелеп килгәнебезне дә онытгым хәтта. Баш табиб рөхсәтен алып, Гүзәл һәм София янына шул көнне үк палатага кердек.

Ул вакытта әти Уфада хастаханәдә иде. Икенче көнне аның янына бардым да: «Әти, мин дә картәти булдым бит», – дидем. Дәшмәде. Карыйм, күзенә яшь тулды. Үзенчә шулай кабул итте.

Бүген әтинең туган көне (интервью көне – 16 февраль). Эшләр күп булуына карамастан, аның янына кайтып килергә вакыт табарга иде. 11 февраль көнне әнинеке булды. Безнең гаиләдә әти һәрвакыт беренче урында, бу культны булдырганы өчен, әниемә зур рәхмәт. Армиядән язган беренче хатымда: «Исәнме, әни, әти...» – дигән булганмын. Әни: «Хатта тәүдә әтиеңне яз», – дип язган иде. Безнең гаиләдә әти кешегә зур хөрмәт. Ә үзе әти назын күрмәгән әтием алдында, миңа тиешле тәрбия биргәне өчен, баш иям. Аңа 11-12 операция кичерергә туры килде, шуңа карамастан Ходай Тәгалә аңа гомерне бирде. Бүген 78 яшь тулды. Әти-әнинең исән-сау булулары минем өчен зур бәхет.

Әңгәмәдәш –
Зоя СОЛОШИНА.

Җәннәткә керүче мәңгелек бәхеткә ирешәчәк

Һәр мөселман кешесенең хыялы – Аллаһының рәхмәтенә ирешеп, җәннәт бакчаларына керү. Әби-бабайларыбыздан ишетеп белгән оҗмах йорты, андагы зиннәтле сарайлар, җимеш бакчалары һәм баллы чишмәләр һәркайсыбызны ымсындырып тора. Шуңа да бу темага җыелган сорауларымны мин даими әңгәмәдәшем – «Өмет» мәчете имам хатибы Равил хәзрәт БИКБАЕВКА бирергә ашыктым.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Җәннәт һәм җәһәннәм Раббыбыз тарафыннан барлыкка китерелгән. Алар хәзерге вакытта инде бар. Җәннәтнең кимчелеге һәм җитешсезлеге һич юк. Аллаһы Тәгалә Коръән-Кәримнең «Сәҗдә» сүрәсендә: «Әгәр Без, теләсәк, һәр кешегә иманны вә һидаятьне бирер идек, ләкин җен вә кешеләрнең имансызлары белән җәһәннәмне тутырачакмын. Минем сүзем хак булды һәм беркетелде», – ди. Шул сүрәдә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Әмма иман китереп изге гамәлләр кылган хак мөэминнәргә Мәэва исемле җәннәт булыр, ул җәннәт чын иманны, хак динне кәсеп иткәннәре өчен аларга мәңге торачак урын булып әзерләнгән». Аллаһы Тәгалә безгә акыл да, сәламәтлек тә, күптөрле нигъмәтләрен дә бирде, эчәргә суыбыз, суларга һавабыз, ашарга ризыгыбыз бар. Боларга өстәп, Коръән иңдерде, безне туры юлга күндерергә пәйгамбәрләр җибәрде, Үзен танытты. Димәк, мөэмин-мөселманнар, Ул кушканнарны үтәп, җәннәткә керергә омтылырга тиеш. Коръәндә аның турында бик күп урында кабатлана. Аллаһы җәннәт белән җәһәннәмне барлыкка китергәч, анда Җәбраил фәрештәне җибәрә. Фәрештә аларны барып карагач, җәннәтне күргән кешенең һичшиксез шунда керәсе килер, җәһәннәмне күргән кеше аннан котылу юлын эзли башлаячак, дигән. Шуннан Раббыбыз җәннәт юлын авырлыклар белән каплап ала, ягъни анда эләгергә ансат булмаячак. Җәһәннәмне, киресенчә, шәһвәт, нәфес белән каплап ала. Сабыр иткән кешегә бу дөньяның ләззәтләрен Раббыбыз җәннәттә бирә. Гомумән анда кешеләрне берәүнең дә күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән, хыялына да кереп карамаган киң нигъмәтләр көтә. Җәннәткә тәкъвалык һәм күркәм холык кертә, дигән хәдис тә бар. Тәкъвалык ул – Аллаһыдан курку, ягъни аның тыйганнарыннан тыелу һәм кушканнарын үтәү. Күркәм холык – таш атканга аш белән кайтару, начар сүз әйтүчегә яхшы сүз әйтү. Иманның күрсәткече намаз уку, ураза тоту, сәдака бирү генә түгел, ә күркәм холык та.

– Хәзрәт, җәннәткә иң беренче һәм иң соңгы булып кем керәчәк?

– Тәүге тапкыр аның ишеген Пәйгамбәребез ачачак. Ахыргы керүчегә килгәндә, ул – җәһәннәмдә иң соңгы булып янган кеше. Сират күпере җәһәннәм өстеннән үтә, ул җиде катлы. Күпер аша узганда, гөнаһлы мөселманнар шунда төшеп бара. Иң өске катта алар яначак, һәм бер вакыт җитәчәк: иң соңгы кеше аннан чыгачак һәм җәннәткә керәчәк. Кемнең күңелендә иман бар, кем Аллаһка ышана, ул җәһәннәмдә мәңгегә калмаячак – җәннәткә керәчәк, имансыз кешеләр генә җәһәннәмдә мәңге калачак.

– Җәһәннәм җиде катлы, дидегез, ә җәннәт ничә катлы итеп эшләнгән һәм андагылар үзләренең ничәнче «этажда» икәнен беләчәкләрме?

– Галимнәр әйтүенчә, аның катлары бик күп һәм кешеләр, гамәлләренә карап, төрле катта булачак. Кеше анда үзен түбән хис итмәячәк, кимсенмәячәк. Иң күп нигъмәт үзенә бирелгән дип уйлый. Җәннәтнең әле сигез ишеге дә бар. Бер ишектән ураза тотучылар керә. Намаз ишеге, сәдака ишеге бар.

– Анда гаиләләр бергә яшәячәкләрме?

– Аллаһы Тәгалә «Тур тавы» сүрәсендә, аталарны балалары белән бергә җыярмын, ди. Балалары биегрәк катка эләксә, үзенең рәхмәте белән, әти-әниләрен шулар янына менгезә. Яки киресенчә, әти-әни янына өскә балаларын да җыячак – бу да алар өчен бер нигъмәт.

– Димәк, ир белән хатын бергә яшәячәк...

– Үзләре моны теләсә, бергә булачаклар. Кемдер бу дөньяда үзенең пары белән бала хакына гына яшәргә мөмкин бит. Ә җәннәттә үз теләкләренә карап кына яшиләр.

– Анда дуслар, туганнар үзара аралашачакмы?

– Дөньяда ничек булганнарын сөйләшеп утырачаклар, дигән аятьләрдән аңлашылганча, үзара күрешеп сөйләшәчәкләр.

– Балалар туачакмы?

– Юк. Әмма сабый вакытта үлгәннәр турында күпчелек галимнәр, барысы да җәннәткә эләгәчәк, дип әйтә.

– Җәннәткә керүчеләр яшәрәчәк икән?..

– «Вакыйга» сүрәсенең 37нче аятенең тәфсирендә, җәннәт кешеләренең барысы да 33 яшьтә булырлар, диелә. Анда керүчеләр кайгы-хәсрәт, авырулар белми һәм мәңге сәгадәттә була.

– Хур кызлары турында нәрсә әйтерсез?

– Иң элек шуны әйтергә кирәк: Аллаһыга гыйбадәт кылган хатын-кызлар хур кызларыннан да матур булачак. «Рахман» сүрәсендә хур кызлары турында «Чатырлар эчендә кара күзле хур кызлары бар» диелә. Алар бик гүзәл, чибәр, пакь булачак, ирләренә генә карап торырлар. Ул хур кызлары гүя якут һәм мәрҗән кеби саф тәнлеләрдер, диелә Коръәндә.

– Анда намаз укыячаклармы?

– Намаз укылмый, ә Аллаһыга зикер-тәсбих итәчәкләр.

– Алар Аллаһны күрәчәкләрме?

– Әйе. Бу иң зур нигъмәт булачак.

– Җәннәт әһелләре нәрсә киеп йөриячәк?

– «Инсан» сүрәсенең 12нче аятендә: «Дәхи аларны Аллаһ юлында чыдамлы булулары өчен җәннәт һәм ефәк киемнәр белән бүләкләр», – диелә. Шул ук сүрәдән аңлашылганча, анда кояш эсселеген һәм суыкны күрмәсләр. Җимешләрне, татлы эчемлекләрне махсус җәннәт егетләре алтын, көмеш савытларда бирәчәк, алар официантлар кебек хезмәт күрсәтә. Дәхи алар янында һич үзгәрми торган яшь егетләр хезмәт итеп йөрерләр, әгәр күрсәң, аларны чәчелгән энҗе данәләре дип уйларсың, диелә 19нчы аятьтә.

– Иң беренче ризыклары нәрсә булачак?

– Зур балыкның бавыры. Аны кайбер галимнәр кит балыгы дип тә әйтә. Йомшак һәм ашарга җиңел ризык булганга, иң беренче аны тәкъдим итәләр. Коръәндә җәннәттә булачак ризыклар исемнәре белән бирелә, әйтик, банан, хөрмә. Әмма алар кеше күзаллавын гына шул исемдә бирелә. Чынлыкта алар тагын да тәмлерәк, башка формада да булырга мөмкин.

– Җәннәт турында күбрәк белергә теләүчеләргә Коръәннең кайсы сүрәләрен укырга киңәш итәсез?

– «Инсан», «Вакыйга», «Рахман» сүрәләрендә аның турында бик тәфсилләп язылган.

Март аена намаз вакытлары

Көн	Көн исеме	Сәхәр тәмам	Мәчетләрдә укыла	Кояш чыга	Зәвәл	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Чәр	04:31	05:04	06:34	11:55	12:00	15:20	17:18	18:59
2	Пән	04:29	05:01	06:31	11:55	12:00	15:22	17:20	19:01
3	**Җом**	**04:26**	**04:59**	**06:29**	**11:55**	**12:00**	**15:24**	**17:22**	**19:03**
4	Шим	04:24	04:56	06:26	11:55	12:00	15:26	17:24	19:05
5	Якш	04:21	04:54	06:24	11:54	12:00	15:28	17:26	19:07
